

АЛДАКЧЫ ТЕЛЕФОН

Мошенникларга ышанып, акчадан колак кагучылар кимеми

> 2

ИЗГЕ ҖАН

Әсгать абый ни өчен бердәнбер, ни өчен аңа тиңнәр юк?

> 3

ҖЫЛЫ УРЫН

Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәгендә эшләп ашарга өйрәтәләр

> 3

НЕФТЬ ҺӘМ РУХИЯТ

«Татнефть» җәмгыяте хәйрия фонды 10 яңа китап белән сөендерде

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 177 (28759) | Шимбә | 4 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

ТӘГӘРМӘЧЛЕ УКЫТУЧЫ

РЕСПУБЛИКАДА ПЕДАГОГЛАР ҖИТМӘҮ ПРОБЛЕМАСЫ НИЧЕК ХӘЛ ИТЕЛӘ?

Алабуга, Чүпрәле, Тукай, Апас, Менделеевск, Биектау, Зәй, Спас районнарында укытучылар кытлыгын хәл итү өчен «Мобиль укытучы» проекты тормышка ашырыла. Авыл мәктәпләренә йөреп белем бирү өчен, район җитәкчелеге укытучыларга машина бирә дигән сүз бу. Мәктәпкә мөгаллимнәрне җәлеп итүнең тагын нинди юллары бар? «ВТ» хәбәрчесе әнә шуларны белеште.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, яңа уку елына мәктәпләрдә педагоглар тупланган, әмма районнарда математика, физика, информатика һәм химия фәннәре буенча укытучыларга кытлык бар. Соңгы биш елда башлангыч сыйныф, рус теле һәм әдәбияты, чит тел укытучыларына ихтыяҗ арткан. Әлегә проблеманы башка фән укытучыларын кабаттан әзерләү, вузларда белем алучы югары курс студентлары, пенсия яшендәге мөгаллимнәр хисабына хәл итәргә туры килә. Мәсәлән, КФУ студентлары – Казан, Ульян педагогика институты шәкертләре Чүпрәле мәктәпләрендә укыта.

– Бездә укытучылар җитә. Барлыгы 420 педагогик хезмәткәр исәпләнә. Шулар арасында мәктәп директорлары, урынбасарлары да бар. Ни өчен дигәндә, алар да 7–9ар сәгать дәрес бирә. Ел саен мәктәпләргә 6–7 яшь укытучы кайта. Алар педагогик вузларга максатчан программа буенча укырга керә. Бу юнәлеш буенча нык эшлибез. Шуңа күрә кадрлар кытлыгы тумый, – диде Чүпрәле районы мәгариф идарәсе башлыгы Илсур Халитов.

Теләче районында да укытучылар җитә икән. Мәгариф бүлеге башлыгы Наталья Карпова, мәктәпкә килергә теләүчеләр табылып тора, ди. Моны ул яшьләр белән актив эшләүдән күрә. Шуңа күрә районда «Мобиль укытучы» кебек проектка да ихтыяҗ юк.

«Мобиль укытучы» программасы авылларда мәктәпләрне саклап калу, кечкенә авылларны укытучылар белән тәэмин итүне күздә тота. Проект буенча укытучыга мәктәпкә йөреп укыту өчен машина бирелә. Бу – бензин, техник хезмәтләр бушка дигән сүз. Моның өчен башта бәйгедә катнашырга кирәк. Әйтик, Алабуга районында биш укытучы арасыннан таләпләргә туры килгән икесен сайлап алганнар. Болар – Мамадыш кызы Алия Фәрхуллина һәм Алабугадан Ольга Пермина.

Шәһәрдә яшәүче Ольга Пермина Хлыстово мәктәбенә йөреп укыта. Моның өчен аңа 11 чакрым юл үтәргә туры килә. Белгечлеге буенча инглиз һәм немец телләре укытучысы ул. Башлангыч сыйныфларга белем бирү өчен квалификациясен яңарткан. Ольга шәһәрдәге мөмкинлекләргә кызыгып, Алабугага ире белән Ижаудан күченеп килгән. Башта Чаллыда укыткан. Декрет ялыннан соң, шәһәрдә эш тапмагач, авылга барырга мәҗбүр булган. Башта болай эшли алырмынмы икән, дип шикләнсә дә, тора-бара ияләшкән. Хлыстово мәктәбендә 18 бала укый. Бер укытучыга – ике сыйныф. Аңа 2 һәм 4 нче сыйныф укучыларын кушып укытырга туры килә. Башта авыррак булса да, хәзер җаен тапкан. Сыйныфта рус, татар, әрмән балалары укый.

– Миңа хәзер автобуска ашыгырга кирәкми. Машина булгач, үземнең вакытны көйли алам. Сәламәтлеге буенча өйдә белем алучы дүрт бала бар. Моңа кадәр алар янына укытырга җәяү бара идем, хәзер анысы да хәл ителде. Бер ел автобуста йөргәч, «Мобиль укытучы» грантында катнашырга булдым. Мондый программалар бик кирәк. Техника булгач, төрле мәктәпләргә барып укытырга мөмкин. Авылга барып укытуның бер кыенлыгын да күрмим. Тик өйгә кайткач, эш буенча машина белән башка җиргә барырга ярамый. Укытудан баш тарткан очракта техниканы кире кайтарырга кирәк, – ди 37 яшьлек Ольга Пермина.

Грант отучының икенчесе – Мамадыштан килеп, физика, математика фәннәрен укытучы Алия Фәрхуллина. Ул быелгы уку елында Костенеево һәм Морт мәктәпләрендә эшли.

Костенеево мәктәбендә 67 балага 17 укытучы белем бирә. Директор Чулпан Гыйззәтуллина әйтүенчә, яңа уку елына мәктәп кадрлар белән тәэмин ителгән.

– Физика, математика укытучысы лаеклы ялга киткән иде. Аның урынына Мамадыштан Алия Фәрхуллина килде. «Мобиль укытучы» – бик уңайлы проект. Бер районнан икенчесенә дә йөреп эшләп була. Бензин бәясе кыйммәт бит хәзер. Ә болай бу чыгымнар өчен акча түләргә кирәкми, – ди директор.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Син – миңа, мин – сиңа. Районнар арасында укытучылар җитмәү мәсьәләсен әнә шул рәвешле дә хәл итәргә туры килә. Балтач районының Бөрбаш мәктәбе белән Кукмара районының Лельвиж мәктәбе әнә шундый килешү төзегән. Бөрбаш мәктәбе директоры Мәлик Сибагатуллин белдергәнчә, әгәр вазгыять үзгәрмәсә, авыл мәктәпләре укытучысыз калачак.

– Өлкән укытучылар пенсиягә китә, яшьләр укытырга килми. Авылдан шәһәргә киткән ике укытучы күченеп кайтты. Математика, информатика укытучысын Казаннан үзем чакыртып кайтардым. Икенчесе гаиләсе белән Чаллыдан күченде. Мәктәпкә биш ел эчендә бары ике генә яшь укытучы кайтты. Элек ун укучының икесе укытучылыкка укырга керә иде. Хәзер баручылар юк диярлек. Кукмара районы мәктәбенә мин – информатика, ә Лельвиж мәктәбе безгә рус теле укытучысын җибәрде. Ике ара – 12 чакрым тирәсе. Менә шундый алыш-биреш ясарга туры килә. Аларга да җиңел түгел. Әгәр машина бирелсә, килеп йөрү уңайлырак булыр иде, – ди Мәлик Сибагатуллин. – Хезмәт хакы аз булгач, яшьләр укытучы булырга атлыгып тормый. Аларга өй салу, фатир бирү дигән нәрсә дә юк. Процентсыз кредитлар бирү мәсьәләсен дә карарга кирәк. Укытучыга таләпләр зур. Укытучыдан укучыларның «4ле» һәм «5ле»гә укуын таләп итәләр. Элек начар укучыларны сыйныфта кабат утыртып калдыру гадәте бар иде, хәзер «2ле»гә укыса, укытучы гаепле. Укыту программаларын да кабат карау кирәк. Әгәр бу проблемалар хәл ителмәсә, мәктәпкә кайтырга теләгән укытучылар саны күпкә кыскарачак.

Сәрия МИФТАХОВА

Министрлыкка тикшерү килә

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Яшьләр эшләре һәм Урман хуҗалыгы министрлыкларында коррупциягә каршы тикшерү барышында ачыкланган закон бозу очраклары буенча тикшерүләр үткәрергә кушкан. Бу эшне оештыру республика Хөкүмәте башлыгы Алексей Песошинга йөкләнгән.

Президентның Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе баш киңәшчесе Салават Рәхимов әйтүенчә, 9 айда махсус комиссия 44 районда, шулай ук 5 министрлыкта тикшерүләр уздырган. «Сәләт» оешмасында һәм Татарстанның ау хуҗалыкларында закон бозуга юл куелу билгеле булган.

Әйтик, идарә хезмәткәрләре дәүләт хисабына яшәүче «Сәләт» фонды эшчәнлегендә 2 миллион сумга төрле чатаклыклар тапкан. Аерым алганда, Биләрдә яшьләр форумын уздыру өчен документларда күрсәтелгәннән арзанлырак палаткаларның сатып алынуы ачыкланган.

Газны бушлай кертәләр

«Татар-информ»

Татарстанда ел азагына кадәр 700ләп йортка газ кертү күздә тотыла. Тагын 8,5 мең йортка «зәңгәр ягулык» киләсе елда киләчәк. РФ Дәүләт Думасының Кече һәм урта эшмәкәрлек комитеты рәисе беренче урынбасары Әлфия Когогина шулай дип белдергән. Аның әйтүенчә, Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча тормышка ашырылучы социаль газлаштыру программасына аерым игътибар бирелә. «Республика бу мәсьәләдә алдынгылар сафында бара. Президент куйган бурычны вакытыннан алда үтәячәгебезгә ышанам», – дигән ул Татарстан Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында узган киңәшмәдә.

Ике шәһәр унлыкка кергән

Чаллы һәм Түбән Кама 2020 ел йомгаклары буенча Россиянең социаль-икътисади яктан алга киткән моношәһәрләре унлыгына кергән. Быел барлыгы 321 шәһәр бәяләнгән. «Иң яхшылар унлыгы – үрнәк алырлык шәһәрләр бу, – дигән Моношәһәрләрне үстерү фонды генераль директоры Ирина Макиева бүләкләү тантанасында. – Безнең моношәһәрләр бер урында гына таптанып тормый, алар һәр ел саен көчлерәккә әйләнә».

Моношәһәрләрне үстерү фондыннан бүләкне беренчеләрдән булып Чаллы мэры Наил Мәһдиев алган. Аның әйтүенчә, бүген моношәһәрләрнең эшләве батырлыкка тиң. Түбән Камадан тантанада район башкарма комитеты җитәкчесе Рамил Муллин һәм элекке мэр Айдар Метшин катнашкан.

Көн кадагында

«Омикрон»га әзер, Яңа елга – юк

Бу сүзләрне дә ишетер көннәр бар икән. Татарстанда коронавирус инфекциясеннән авыручылар саны кимү күзәтелә. Аз булса да, үзгәреш бар. Тик ул бер мизгелдә үзгәрергә дә мөмкин.

Узган тәүлектә коронавирус йоктыручылар саны 236га җиткән иде. Бу алдагы көннең күрсәткеченнән 34кә азрак. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина әйтүенчә, соңгы 11 атнада беренче мәртәбә күзәтелгән үзгәреш бу. Үсеш темпы 5,5 процентка кимегән.

Аның каравы, грипп белән авыру очраклары арта. Узган атнада Татарстанда авыруның 14 очрагы теркәлгән. Гомумән алганда, республикада шундый 29 очрак бар. Белгечләр алга таба грипп белән авыручылар арту ихтималын да фаразлый. Любовь Авдонина искәрткәнчә, халыкка кичекмәстән грипкка каршы прививка ясатырга кирәк.

Роспотребнадзорның даими тикшерүләренә килгәндә, идарә вәкилләре ноябрь аенда 1287 объектны тикшергән (чагыштыру өчен: октябрьдә 935 тикшерү). Һәр бишенчесендә кагыйдә бозу ачыкланган.

– Бу – 263 объект, ягъни тикшерелгән объектларның 20 проценты. Алар таләпләрне бозып эшчәнлек алып барган. Октябрьдә бу күрсәткеч 17 процент иде, – диде Любовь Авдонина. Идарә хокук бозучыларга карата 252 беркетмә төзегән һәм якынча ике миллион сум күләмендә штраф салган. 8 объектның эшен туктатканнар.

Таләпләр үтәлмәгәч, чикләүләрне киметү турында да сүз була алмый. Роспотребнадзорның җәмәгать туклануы объектларына Яңа ел төнендә озаграк эшләү мөмкинлеге бирәсенә өметләнмәскә дә буладыр.

Яңа ел димәктән, идарә вәкилләре Татарстан районнарында бәйрәм чаралары үткәрү форматы турында уртак фикергә килмәгән. Бу сорауга җавапны 10 декабрьдән дә иртәрәк ишетеп булмаячак әле.

Моңа өстәп, Любовь Авдонина балалар бакчаларындагы Чыршы бәйрәмнәрен үткәрү буенча кагыйдәләрне дә искә төшерде. Чараларда күпләп җыелуны булдырмас өчен, бәйрәмдә баланың йә әтисе, йә әнисенә генә катнашу рөхсәт ителә. Аның QR-коды булырга тиеш. 60 яшьтән өлкәнрәкләргә бәйрәмнәргә килмәскә киңәш ителә. Шулай ук температура үлчәү, битлек кию режимы, социаль ара саклау кебек таләпләр дә үтәлергә тиеш. Балалар бакчасына аниматор, бәйрәм оештыру белән шөгыльләнүче чит хезмәткәрләр кертелмәячәк.

Яңа елны каршыларга әзер булмасак та, «омикрон»га әзер икән. Билгеле булганча, дөньяда коронавирус инфекциясенең яңа штаммы – «омикрон» дигәне тарала башлады. Республиканың сәламәтлек саклау системасы вазгыятьне контрольгә алырлык хәлдә булуын әйтте.

– Ай ярым вакыт узгач килерме, бөтенләй булмаса да, бик яхшы. Әйдәгез, карап карыйк. Һәрхәлдә, сәламәтлек саклау системасы моңа әзер, хастаханәдә урыннар бар, – диде Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков.

Сүзгә-сүз

Рабит БАТУЛЛА, язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе:

Язучыларның 90 процентының балалары татарча белми. Әтисенең язганнарын укый алмый. Аяз Гыйләҗев, Нурихан Фәттахның балалары татарча белем-тәрбия алды, дип әйтә алам. Карагыз Аяз абыйның балаларын: берсе галим, берсе язучы булып китте. Алар татар сәнгатенә хезмәт итәләр.

(«Татарстан» журналы)

ТАТАРСТАНДА – ЯШЬЛӘР

2021 ел башында Татарстанда яшьләр саны 1072,9 мең булган. Татарстанстат мәгълүматларына караганда, бу республикада яшәүче бар халыкның 27,6 процентын тәшкил итә.

АВЫЛДА 234,8 мең	КЫЗЛАР 535,5 мең
ШӘҺӘРДӘ 838,1 мең	ЕГЕТЛӘР 537,3 мең

КАЗАНДА 365,6 мең

Кәгазьдәгесе тарихта кала

Киләсе елдан электрон «больничный» мәҗбүригә әйләнә. Кәгазьдәге «больничный» тарихта гына калачак дигән сүз бу. Шул ук вакытта хезмәткә вакытлыча яраксызлык буенча түләүгә мөрәҗәгать итәргә кирәк булмаячак. Аны инде бүген үк Социаль иминиятләштерү фонды турыдан-туры күчерә.

Әмма әлегә хезмәткәргә җитәкчесенә үзенең чирләп китүе, «больничный»ның кайчан ачылуы һәм ябылу турында белдерү кирәк. Киләсе елда исә, чирләп киткәндә, эшкә килә алмауны дәлилләп торасы булмаячак. Бу хакта Социаль иминиятләштерү фондына поликлиникадан хәбәр җибәреләчәк. Фонд, үз чиратында, бу хакта эш бирүчегә хәбәр итәчәк.

Эш шунда: киләсе елның 1 гыйнварыннан эш бирүчеләрнең барысы да Социаль иминиятләштерү фондының электрон документлар әйләнеше системасына тоташтырылырга тиеш. Фонд шуның аша эш бирүчегә авырып киткән хезмәткәренә «больничный» ачу, озайту яки ябу турында хәбәр бирәчәк. Кирәк булганда, «больничный» түләү өчен мәгълүматлар, мәсәлән, кешенең хезмәт хакы күләмен, стажын сорап алачак.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Тәмамланмаган сугыш

Сугыш кайчан тәмамланган санала? Һәлак булган соңгы солдат җирләнгәч. Язылмаган бу канун канкоеш дәвамлы, масштаблы булып, кемнәрдер вакытында җиргә иңдерелмичә калганда, сугыш бетүгә үк, алар хөрмәтләп күмелергә тиешлекне аңлата. Язып торуларынча, Россиянең төньяк-көнбатыш өлкәләрендәге урман, сазлыкларда әле бүген дә Бөек Ватан сугышында һәлак булган солдат һәм офицерларның күмелмәгән сөякләре ята. Кайда күренеп, кайда ярты, бер карыш җир катламы астында. Аларның якынча саны да билгеле: ярты миллион (!) тирәсе. Димәк, сугыш әле туктамаган, бара булып чыга. Җиңүнең инде ничәнче еллыгын билгеләп үтүебезгә дә карамастан…

Бу юлларны мин кичәге датага – Билгесез солдат көненә бәйле рәвештә язам. Төрле истәлекле һәм бик үк истәлекле булмаган көннәр бездә бихисап хәзер. Ләкин алда әйтелгән дата – аерым, ул ниндидер симерүгә каршы көрәш көне, хәтта физкультурачы яисә иминиятче көне белән бер яссылыкта түгел, була да алмый. Ул – 2014 елда Дәүләт Думасы кабул иткән, Президент кул куйган канун нигезендә гамәлгә кертелгән көн. Тик башка истәлекле даталардан югары тора дисәк тә, бу юнәлештә ел саен изгедән-изге гамәлләр кылына, 3 декабрь җитүгә, башкарылганнарга зурдан кубып нәтиҗә ясала, дип һич әйтеп булмый. Бабаларыбызны, алар батырлыгын хөрмәт иткән тәкъдирдә без инде күптән, дата билгеләнгәнче үк, җир куенына салынмаганнарның санын елдан-елга киметә барырга, билгесезләрне мөмкин кадәр билгеле итәргә, туганнарына тиешле мәгълүмат җиткерергә тиеш идек бит.

Күпме еллар үтеп тә, шулкадәр солдат сөякләре ник һаман кадерсез? Ил өчен үлгәннәрнең кабере һәм кадере булмау исәннәрнең олы сансызлыгы, хәтта оятсызлыгы түгелме? Без бит барыбыз да – адәм балалары, Җиргә яшәргә, булдыра алганча бәхетле булырга, балалар үстерергә, оныклар сөяргә дип киләбез. Тик беркөнне сугыш чыга, демобилизация башлана, фронт, канкоеш – өйләнергә дә өлгермәгән ир-егет, Ватанны саклап, дөнья белән хушлаша. Ватан өчен үлү үзе генә дә – олы батырлык, фидакарьлек. Бабаларыбыз батырлыгын безнең бүгенге битарафлык капларга һич тә тиеш түгел. Сугыш барганда, төрле сәбәпләр аркасында, солдат кешечә гүргә төшерелмичә, хәтта туганнар каберлегенә дә эләкмичә, җир өстендә ятып калырга мөмкиндер анысы. Тик сугыш иртәме, соңмы туктый. Менә шул чакта адәм рәтле дәүләт, бар эшен ташлап, мәрхүмнәрне табу, исемнәрен ачыклау, җирләү белән шөгыльләнә башларга тиеш. Соңгы солдаткача. Кабересезләр, язмышын, кай тарафларда, нинди шартларда ятып калганын туганнары белмәгәннәр сирәктән дә сирәк күренеш булсын өчен. Намусыбыз чиста торсын, ватанпәрвәрлек буш сүз булып калмасын өчен.

Патриотизм турында бездә сүз сөйләнелә. Төрле юллар белән аны тәрбияләргә тырышалар, күп акча тоталар. Кайчагында артыгын да кыланып ташлыйлар. Зурлыкны бөеклек белән бутыйлар, телевизор әйткәнне хакыйкатьнең соңгы стадиясенә чыгаралар. Ил тарихы да данлы вакыйгалардан гына тора, дип ышандырырга тырышалар. Сугыш турындагы бала чакта караган фильмнар, андагы чамасыз ясалма героизм, хәтта ки романтизм искә төшә. Немецлар барысы да тилемсә, аңгыра, сугыша да белмиләр, безнекеләр – тоташ геройлар, шуңа гел җиңеп киләләр. Андый ура-патриотизм әле дә җитәрлек. Шул исәптән киноларда да. Берничә ел элек кенә төшерелгән «Т-34» фильмын караганнар моны яхшы сизгәндер. Ә кемнәрдер сизмәскә дә мөмкин.

Андыйлар Җиңү көне якынлашкан вакытларда машина пыяласына «Кабатлый алабыз» («Можем повторить») дип язып куя. Нәрсәне кабатлый аласыз? Алда искәртелгән ярты миллионнымы? Әллә 27 миллион гомуми югалтуларнымы? Мондый гөнаһлы язулар ничек, ни сәбәпле туа соң? Сорауга җавап билгеле кебек. Сугышның чын сурәтен, ачысын белмәгәнгә, аны бары тик героизмнан гына тора, дип күрсәткәнгә, романтика дәрәҗәсенә җиткергәнгә ярала алар. Андый затларга – сукыр, ясалма ватанпәрвәрлек тудыручыларга – һәрчак сугышның башыннан азагына кадәр үткән язучы Виктор Астафьев әйткәннәрне ирештерәсе килә. «Те, кто врет о войне прошедшей, приближают войну будущую. Ничего грязнее, жестче, кровавее, натуралистичнее прошедшей войны не было. Надо не героическую войну показывать, а пугать, ведь война отвратительна. Надо постоянно напоминать о ней людям, чтобы не забывали. Носом как котят слепых тыкать в нагаженное место, в кровь, в гной, в слезы, иначе от нашего брата ничего не добьешься». Фронтовик язучы ясалма патриотизм градусын киметергә, уяу булырга өндәп кенә калмый, хәтерсез, сансыз булмаска да куша.

Туганнар каберлегендәге монументларда еш кына «Беркем дә, бернәрсә дә онытылмады» («Никто не забыт, ничто не забыто») дигән язулар укыйбыз. Алда әйтелгән ярты миллион (бу бит – тулы комплектлы 50 дивизия дигән сүз) – җеназасыз, каберсез ятканда, бу гыйбарәдә дә икейөзлелек юкмы? Маршал Иван Конев үз мемуарларында, сугыш алдыннан үткән бер хәрби киңәшмәдә һәр полкта җирләү командалары булдыру тәкъдиме белән чыгуын, тик Ворошилов, Буденныйның аңа теләктәшлек күрсәтмәвен, Сталинның исә: «Безнең данлы Кызыл Армия дошманны үз территориясендә аз санлы югалтулар белән тиз арада тар-мар итәчәк, андый командаларга ихтыяҗ күрмим», – диюен яза. Юлбашчының тиз дигәне дүрт елга сузылганы, югалтуларның тарихта гомумән тиңе булмавы, җирләү командаларына ихтыяҗның ни дәрәҗәдә зур булганы хәзер яхшы билгеле…

Миңа калса, җир өстендә калган солдат сөякләре, сугыштагы коточкыч югалтулар кебек үк, кеше бәясенең шактый түбән булуы белән аңлатыла. Бигрәк тә совет чорында, аның беренче яртысында. Бәндә тыныч шартларда – эш аты, сугышта – туп ите. Бүген күп чыганаклар данлыклы, җиңү маршалы саналган икенче бер хәрби җитәкченең һөҗүм алдыннан генералларга кабатларга яраткан сүзләрен китерә: «Сугышчыларны җәлләмәскә, сугыштан соң хатын-кызлар баланы кирәгенчә табачак!» («Бойцов не жалеть, после войны бабы нарожают сколько надо!») Билгесез солдатлар, аларның күплеге, үлгәннәрнең һаман да җир өстендә калуы, сугыш китергән бәлаләр булудан бигрәк, гомуми кадерсезлеккә, исәннәргә дә кадер булмауга кайтып калмыйммы?

БҮЛӘККӘ – ВАКЦИНА

Яңа елга яңа көч белән һәм прививкалы килеш керик. Кирәк булса, Кыш бабай килеп, үзе вакцина ясаячак. Россия Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов «туры эфир» барышында шулай дип шаяртты. Мәзәк нигезендә дөреслек тә ята: Кыш бабай урынына медицина хезмәткәрен җәлеп итеп, ихтыяҗ булган кешеләргә вакцина ясатырга ярдәм итәчәкләр. Моны Яңа ел бүләге кебек кабул итәргә дә мөмкиндер, ди депутат.

«Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы иҗтимагый кабул итү бүлегенең «Инстаграм» сәхифәсендә сәламәтлек һәм COVID-19 инфекциясе таралу алган чорда медицина ярдәмен күрсәтү турында «туры эфир» узды. Депутатлар, сәламәтлек саклау, Роспотребнадзор һәм башка тармак вәкилләре көн кадагында торган сорауларга җавап бирергә тырышты.

– Әле шушы көннәрдә генә 20 еллыгын билгеләп үткән партиябез безгә ышанганнарның мөрәҗәгатьләренә мөмкин кадәр тиз, төгәл итеп җавап бирергә тырыша. Табиб та, сәясәтче буларак, минем үземә дә көн кадагында торган әлеге мәсьәләгә бәйле йөзләп мөрәҗәгать кабул итәргә туры килә, – диде онлайн очрашуны алып барган Айрат Фәррахов.

Аның сүзләренчә, коронавируслы чорда халыкның сораулары да, рәхмәт сүзләре дә шактый җыелган. Депутат аларны очрашуда катнашкан хезмәттәшләренә җиткерде.

Коронавирус белән чирләп, хастаханәгә эләккән кеше белән элемтә өзелергә мөмкин. Аңлашыла: медицина вәкилләренең дә телефон янында гына утырырга вакытлары булмаска мөмкин. Моңа карап кына сырхауның туганнарының борчуы басылмый бит. Андый очракта нишләргә?

Татарстан буенча Росздравнадзор идарәсе җитәкчесе Любовь Шәйхетдинова әйтүенчә, күп сораулар мәгълүмат җитмәгәнлектән туа. «Табиб серен саклау» дигән төшенчә бар. Шуңа да барлык хәлләр турында мәгълүмат тарату мөмкин түгел. Бу гадәти чорда да, пандемия вакытында да шулай. Моңа да карамастан, кизү торучы хезмәткәр, колл-үзәк булдыру зыян итмәс иде. Борчылып торганнарны тынычландырырга кирәк бит», – диде ул. Сырхаулар бу сорау белән идарәнең «кайнар элемтәсе»нә **(8(843) 292-54-37)** дә мөрәҗәгать итә ала.

АЛДАКЧЫНЫ ҖИҢӘМ, ДИМӘ

Казанда яшәүче бер хатын, кырыгалдарлар сүзенә ышанып, үз исеменә берьюлы ике (!) кредит рәсмиләштергән. Шул рәвешле ул барлыгы 382 мең сум акчасыннан колак каккан!



pixabay.com

Ноябрь азагында аңа ят номердан шалтыратканнар. Үзен банк хезмәткәре дип таныштырган хатын-кыз. «Күптән түгел генә кредит рәсмиләштермәдегезме? Паспортыгызны югалтмаган идегезме?» ише сораулар яудыра башлаган. Аптырап калган хатын «юк» дип трубканы куймакчы була. Банк хезмәткәре исә аңа шундук банк картасының номерын һәм арттагы CVV-кодны әйтеп бирә. Шуннан хатын үз исеменә дөрестән дә кредит алганнар дип уйлый. Банк хезмәткәре аңа кырыгалдарлар рәсмиләштергән шушы кредитларны тиз арада ябу өчен, яңа ике кредит ачып, аннан килгән акчаны, бурычны каплау өчен банкка җибәрергә киңәш итә. Шулай эшлиләр дә. Үзенә ике кредит рәсмиләштергәч, телефоннан сөйләшкән хатын-кыз әйтеп торган счетка көн буе акча күчергән ул. Шунда ук телефонына «Кредитны уңышлы яптыгыз» дигән смс-хәбәр килә аның. Күңеленә шик кереп, тикшерә торгач, бу ханым чынлыкта үз исемендә элеграк берниндн кредит та булмавын, аның каравы, яңасын рәсмиләштереп, 400 мең сумыннан колак кагуын аңлап алган.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, республикада көненә уртача 30 кеше телефон аша алдана. Россия күләмендә исә телефон аша һәр ун шалтыратуның берсе кырыгалдарлар өлешенә туры килә икән. Быелның тугыз аенда ил күләмендә телефон аша алдануның 163,2 мең очрагы теркәлгән. Бу – узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 5 процентка күбрәк. Телефон номерын үзгәртеп шалтырату – соңгы арада мошенниклар тарафыннан иң еш кулланылган төп башына утыртту алымы, ди белгечләр. Алдакчылар хәтта кешенең туган-тумачасы номерыннан да ярдәм сорап шалтырата башлаган. Шулай да күбесе үзен банк хезмәткәре дип таныштыра икән. Телефон аша алдау очракларының 80 проценты нәкъ менә шуңа туры килә.

Быелның өченче кварталында Россия Үзәк банкы кырыгалдарлар кулланган 24,4 мең телефон номерын юк иткән. Шуларның 19 меңен – стационар, калганын кесә телефоны номерлары тәшкил итә. «Элемтә турында» законга кертелгән төзәтмәләр нигезендә, шикле номерларны операторлар үзләре үк юкка чыгарырга тиеш. Законга төзәтмәләр 1 декабрьдән гамәлгә керде инде. Хәзер операторлар телефон номерын иң элек бердәм идентификация һәм аутентификация системасына кертергә тиеш. Базадагы юридик зат һәм шәхси эшмәкәрләр номерлары белән чагышмаган SIM-карталар эшләми башлаячак.

Аналитик Алексей Сизов сүзләренә караганда, телефон аша алдау-алданулар киләсе елда да күп булачак. «Кырыгалдарларның ничек эш итүе, нинди яңалыклар уйлап табуы турында даими сөйләнелә. Әмма шулай да кешеләр һаман алдана бирә. Шуңа күрә кесә телефонына шалтыраткан таныш булмаган номерларны бөтенләй алмавың хәерле», – ди белгеч. Яңа ел алдыннан мошенниклар тарафыннан алданучылар саны бермә-бер артачак, дип фаразлый ул. «Тормыштагы бер генә вакыйганы да күз уңыннан ычкындырмаган кырыгалдарлар бу очракта да акча эшләп калырга ашыгачак. Халыкны төрле отышлы тәкъдимнәр, теге яки бу товарга ташламалар белән кызыктырып, төп башына утыртырга тырышачак алар», – ди Сизов.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Роман Архипов, юрист:

– Статистика буенча бездә телефон аша алдаучы ун кырыгалдарның берсен генә ачыклыйлар. Законга үзгәрешләр кертелү яхшы. Ләкин кырыгалдарлар аларны барыбер урап узу юлларын, яңа алдау ысулларын уйлап табачак. Аларның кайсы номердан шалтыратканын, сез күчергән акчаны кайсы счетка озатканнарын да еш кына табарлык түгел. Эзне бик тиз һәм оста яшерәләр. Сезгә кырыгалдар шалтыратканын сизенсәгез, трубканы шундук куярга кирәк. Алар белән сөйләшкәндә «әйе» дигән сүзне бөтенләй ычкындырырга ярамый. Үзегез турында берничә мәгълүмат та әйтмәгез. Сезгә кем шалтыратканны тикшерү өчен, банкның үзе белән элемтәгә керергә кирәк.

Яшел чыршы, үсә торчы

Икенче ел рәттән без бу бәйрәмнән аеруча могҗиза көтәбез. Әллә шуңа, әле декабрь җиткәнче үк, чыршы бизи башладылар. Шуңа күрә ясалма чыршы сатучылар үз эшенә инде күптән тотынды. Ә менә табигыен алучылар соңгы елларда сизелерлек кимегән. Шуңа күрә быел Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгы чыршы кисеп сату буенча аукцион да уздырмаган.

– Безгә чыршы сатудан файда юк. Урманчылар да агач кисмәү яклы, – ди Казандагы шәһәр яны урманчылыгы җитәкчесе Илнур Кәшәфиев. – Шулай да бәйрәмгә дип, плантацияләрдә һәм питомникларда чыршыларны махсус утыртабыз. Соңгы елларда сораучылар күп түгел. Ихтыяҗ нык кимеде. Күпләр ясалманы бизи. Бу очракта табигатькә зыян салынмый. Әгәр инде чын чыршы куярга телисез икән, аны безнең питомниклар аша алып булачак. Килгән кешегә чыршыны кисеп бирәбез.

Илнур Кәшәфиев әйтүенчә, питомникларга чыршы сорап килүчеләргә аны декабрьнең 20ләреннән соң сата башлаячаклар. Урманчы үзе дә ясалма чыршы бизәү яклы. Әмма Татарстанда чыршы сатарга килүче башка төбәк кешеләре булыр, ди ул. Алардан алганда исә документларына игътибар итәргә киңәш бирә.

Кукмара районында урнашкан Лубян урманчылыгы җитәкчесе Фәрдүс Хәбибрахманов та чыршыны сораучы булмагач, сатудан файда юк, дигән фикердә.

– Урманчылар өчен эше күп, акчасы юк аның. Чыршы сату үз-үзен акламый. Алам дигән кешегә китереп сатучылар булыр әле, – ди ул.

Дөрестән дә, халыкның чыршыга исе китми башлады. Балык Бистәсендә яшәүче Зөлфирә Идиятова, элек чыршыны урманнан гына алып кайтып куя идек, ди.

– Әти ел саен урманнан кисә дә алып кайта иде. Без, балалар өчен, бу могҗиза төсле тоела иде. Урманнан кайткач, аның ниндидер сихрилеге бар кебек иде. Ул чагында урманчылар да тикшермәгән, штраф та салучы булмаган, – ди ул.

Хәзер исә рөхсәтсез урманга керәм димә. Татарстанда озакламый «Ель» дип аталган махсус тикшерү чарасы башланып китә.

Рөхсәтсез чыршы кисүче физик затларны – 3 меңнән 4 мең сумга, вазыйфаи затларны – 20 меңнән – 40 меңгә, юридик затларны 200 меңнән – 300 мең сумга кадәр штрафка тартырга мөмкиннәр. Әле ул кеше табигатькә китергән зыянны да капларга тиеш була. Моның өчен тагын өстәмә 5 мең сум күләмендә штраф салына һәм җинаять эше ачыла.

Ясалма чыршыны теләсә-нинди сәүдә үзәгеннән, кибетләрдән сатып алырга була. Аның бәясе биеклегенә карап 1 меңнән 20 мең сумга кадәр. Чын чыршының да бәяләре узган елгыдан бераз кыйммәтрәк. Элек бер метры 400 сум булса, быел ул 550 сум тора. Ике метрлысын – 700, 3 метрлысын 1100 сумга алып була. Урманчылар 11 метрлы чыршы да кисеп бирә ала. Аның бәясе 4500 сум икән. Зәңгәр чыршы исә кыйммәтрәк йөри. Аның бер метры – 1400 сум, 4 метрлысын 2500 сумга бирәләр.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

«ӘБИ-АПАЛАР КЫЗГАНЫЧ»

Ике атна элек Тукай районында кош гриппы ачыкланды. Әлеге авыру фермер Эдуард Фролов хуҗалыгында табылды. Ул вакытта 42 мең баш бытбылдык, 171 кг ит һәм 48 мең йомырка юк ителде. Шулай ук Яңа бистә, Калмаш, Югары Байлар авылларында барлыгы 1470 тавык, 9 үрдәк, 7 мисыр тавыгы, 1068 каз яндырылды.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстан Президенты указы нигезендә районда карантин игълан ителде һәм шушы торак пункт тирәсендәге авылларда да кош-корт юкка чыгарылырга тиеш дигән карар чыгарылды. Бөтен авыру кош, азык, кош тизәкләре-тиресе яндырып юк ителде. 21 көн эчендә кабат авыру чыкмаса, кошчылык хуҗалыгында ахыргы дезинфекция ясалачак.

Калмаш авыл җирлеге башлыгы Равия Габдуллина безгә әлеге мәшәкатьләрдән шактый арыганлыгын әйтте.

– Дөресен генә әйткәндә, бу хәлләр ялкытты инде, – диде ул безгә. – Авылыбыз шактый зур. Авыру табылган көнне үк авылдагы барлык кош-корт юк ителде. Бу күренеш кемгә ошасын инде? Халыкның кәефе кырылды, билгеле. Әлеге вакытта алар компенсация алыр өчен документлар тапшыру белән мәшгуль. Дүрт ай узгач кына яңа кош-корт алырга рөхсәт булачак. Халык компенсация алгач, кабаттан тавыклар үрчетергә ниятли.

Тукай районында «Мусабай» зур кошчылык кооперативы эшли. Аларга да шалтыратып, хәлләрен белештек.

– Безнең барысы да яхшы. Дөресен әйткәндә, проблемасына караганда шаушуы күбрәк булды, – диде хуҗалык җитәкчесе Айгөл Ханова. – Районда кош гриппы ачыклану безнең эшебезгә берничек тә йогынты ясамады. Ничек эшләгәнбез, шулай дәвам итәбез. Тиздән кош чалу цехын эшләтеп җибәрергә планлаштырабыз. Ә халык чыннан да кызганыч. Авылда яшәүче әби-апаларның күңел юанычы, сәламәт ризыгы бит ул. Җәй буе тырышып үстергән кош-кортларын төяп алып чыгып киткәч, борчылмый нишләсеннәр!

Зыян күргән хуҗалыкларга компенсация түләнәчәген Татарстан Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең терлекләрдәге йогышлы авырулар һәм эпизоотиягә каршы чараларны оештыру бүлеге җитәкчесе Елена Ильина да раслады. Компенсация күләме Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының рәсми җавабы нигезендә билгеләнә.

– Бәясен төгәл генә әйтеп булмый. Халыктан алынган вакытка кошның базардагы бәясе күпме булса, шулкадәр компенсация биреләчәк. Хәзер бу эшләрне башкарып чыгар өчен документлар әзерлибез, – диде Елена Ильина.

Ветеринария белгечләре әйтүенчә, кош гриппы чыккан хуҗалыкта дезинфекция һәм барлык кирәкле чаралар уздырылган.

– Шәхси хуҗалыкларда дезинфекция үткәрелми. Кош гриппы табылган урыннан биш километр ераклыкта урнашкан авыллардагы кошлар юк ителде, – диде белгеч.

Мондый хәлләр башка район, авылларда кабатланмасын өчен нәрсә эшләргә соң?

– Кош-корт тотучыларга көзге айларда тагын да игътибарлырак булырга кирәк, дип гел әйтеп киләбез. Хәзер барлык кошларны да ябып куярга кирәк, урамга чыгарырга ярамый. Каз өмәләрен дә бу вакытка кадәр калдырмау яхшы. Йорт кошларын синантроп кошлардан – чыпчык, карга, чәүкә, күгәрчен, саесканнардан сакларга кирәк. Кошларның халәтен дә күзәтеп торырга кирәк. Кошларга грипп эләксә, алар үлә башлый. Әгәр кошлар гадәттән тыш тынычсызланса, борын тишекләреннән сыеклык акса, кикрикләре зәңгәр төскә керсә, ветеринарларга мөрәҗәгать итәргә кирәк, – дип киңәш бирә ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

«УЛ – БЕРДӘНБЕР, АҢА ТИҢНӘР ЮК ӘЛЕ»

Әсгать Галимҗанов турында затлы китапны кулга алгач, Дәүләт киңәшчесе Минтимер ага Шәймиевнең атаклы хәйрияче турында әйткән сүзләре уйландырды. Әсгать абый ни өчен бердәнбер, ни өчен аңа тиңнәр юк? Китапны укып чыккан кеше бу сорауларга җавап табар.

Үзе исән чакта Әсгать абый турында төрле сүзләр йөрде, аның турында сәер дип әйтүчеләр дә булды. Әмма бу сүз яхшы мәгънәдә кабул ителә иде. Чөнки үзе баракта яшәгән бу шәхес гомер буе балаларга булышты: ятимнәр йортларына акча күчерде, машиналар, автобуслар бүләк итте. Юкса, эшләгән акчасына үзе өчен менә дигән сарайлар да салып куя ала иде ул. Әйе, мондый кеше күпләргә сәер тоелды, аның эшчәнлегенә бүген дә шаккатабыз. Һәм әлеге китап Әсгать Галимҗанов исемен тарихта калдырырга, аның турында халык хәтерен озайтырга ярдәм итәчәк дип уйлыйбыз.

Шунысын да әйтик: «Изге җан. Лучший из нас» дип аталган китапны төзүче Габделбәр Ризванов «Ватаным Татарстан»да (элекке «Социалистик Татарстан») эшли һәм Әсгать абый турында иң беренче мәкалә дә безнең газетада басылып чыга.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Герое белән беренче очрашуы да кызык булган Габделбәрнең. Хатыны Асия Райпищеторгта бухгалтериядә эшләгәндә, аларга Әсгать абый кергәләп йөри. Һәм беркөнне балалар йортына акча күчерү турындагы документларын онытып калдыра. Асия аларны карый да шакката. Үзе бик гади киенгән абзыйның ятимнәргә ярдәм итүенә шакката ул һәм, өйгә кайткач, әлеге «сәер кеше» турында иренә сөйләп бирә. Журналист кеше мондый гыйбрәтле хәлгә битараф каламы соң? Габделбәр Асиясе белән Әсгать абыйның өенә бара һәм шул танышу зур дуслыкка әверелә. Габделбәр исә Әсгать абыйның һәр изге гамәле турында газетада мәкаләләр бастыра башлый. Тора-бара аңа башка журналистлар, рус телендә язучы каләмдәшләребез дә кушыла, радио-телевидение журналистлары аерым тапшырулар эшли башлый. Ә Әсгать абый, гаять тыйнак кеше буларак, үз тирәсендәге мондый шау-шуны бик өнәп бетерми. Күрәсең, мохтаҗларга ярдәм итүне ул табигый хәл, шулай булырга тиеш, дип саный.

Күңеленә каян килгән шундый изгелек? Габделбәр миңа бер кызыклы хәл сөйләде әле. Берара Әсгать абый милициядә эшләп алган. Замнында сәрхушләрне айныткычларга ташу бар иде бит. Әсгать абый, исерекләрне айныткычка тапшыру урынына, аларның адресларын сорашып, өйләренә илтеп куя торган булган. Әлбәттә, милиция җитәкчелегенә бу кыланмышлары ошамаган һәм аны: «Син безнең кеше түгел!» – дип, эшеннән азат иткәннәр ди. Күрәсең, изгелек дигәннәре кеше күңеленә Аллаһы Тәгаләдән салына торгандыр инде. Әсгать абый, ат җигеп, төрле кибетләргә ашамлык-ризык ташый башлый. Ишегалларында аунап яткан ризык калдыкларына йөрәге әрни аның һәм шуларны җыеп, терлекләргә ашата. Маллар симертеп сата да акчасын балалар йортларына җибәрә башлый.

Габделбәр әйтүенчә, малларга дип, Кремль тирәсендәге үләнне дә чаба ул. Аның изгелекләре турында күреп-ишетеп белгән Минтимер ага хәйриячегә терлек асрау өчен бушап калган бер җир бирдертә. Ул җирне «кеше рәтенә» кертү өчен, машина-машина чүп түгәргә туры килә әле. Бернидән дә зарланмый Әсгать абый, эшли дә эшли. Аның дуңгыз симертеп сатуын өнәмәүчеләр дә табыла. Шул тирәдә яшәүчеләр «яман ис»тән зарланса, мөселман кардәшләр «татарга дуңгыз асрау хәрам» дип тавыш куптаралар. Дуңгыз ите сатудан килгән акчаның ятимнәргә җибәрелүе турында уйлап та карамыйлар. Габделбәр әйтүенчә, Әсгать абыйга симертү өчен малларны төрле хуҗалыклар да бирә башлый. Әлбәттә, инде монда республика җитәкчелеге, аерым алганда Минтимер аганың өлеше дә зур булгандыр, дип уйлыйм. Әсгать Галимҗанов белән үзе дә шактый еш очрашкан ул.

Атаклы хәйриячегә үзе исән чагында ук һәйкәл куйдыртуы да Минтимер аганың хәйриячегә никадәр игътибарлы булуы турында сөйли. Һәйкәл кую – үзе бер гыйбрәтле тарих, аны миңа Дәүләт Киңәшчесенең ярдәмчесе Нурсөя Шәйдуллина сөйләде. Бервакыт Әсгать абый хәйриячелек буенча Совет утырышында сүз ала да, Татарстан Президентына һәйкәл куярга теләк белдерә. Серле генә елмаеп тыңлаган Минтимер Шәймиев, аның фикерен эләктереп алып, гаиләсе белән бергәләп Әсгать абыйның үзенә һәйкәл куйдыра. Шәймиевләр гаиләсе һәйкәл тирәсендәге бакчаны төзекләндерү эшен дә үз өстенә ала, бакчага Әсгать Галимҗанов исеме дә бирелә. Габделбәр Ризванов хәйрияче турында китап чыгарырга ярдәм сорап мөрәҗәгать иткәч, Минтимер Шәрип улы аның идеясен шундук күтәреп ала. Аңа Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов та кушыла. Премьер-министр урынбасары, үзе дә иҗат кешесе, белеме буенча филолог Ләйлә Фазлыева проектның җитәкчесе итеп билгеләнә һәм китапның концепциясенә күп кенә кызыклы фикерләр кертә.

Инде китап төзүдә Нурсөя Шәйдуллинаның үз өлеше дә шактый зур булуын өстик. Китап язмышында республиканың иң югары җитәкчелеге катнашуы Әсгать аганың ни дәрәҗәдә хөрмәткә лаек булуы турында сөйли. Ә шәхсән үзем, мондый шәхес тагын кайсы халыкта бар икән әле, дип тә уйлап куйдым, милләтем өчен горурлык хисләре тагын да артты кебек. Китапның татар һәм рус телләрендә нәшер ителүе дә әйбәт, татарның нинди улы барлыгын күбрәк кеше белсен.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

ЭШЛӘП АШЫЙСЫ

Үзем күрдем

Биредәгеләрне күргәч, күңелгә читен булып китә. Кызганып та булмый аларны, сүгәсе дә килми. Үзләрен тыңлый башлагач, барысына – бер язмыш, диясең. Яшәргә урыннары булмагач, урамда калганнар. Берәүләрен балалары, ире йә хатыны куып чыгарган, икенчеләре төрмәдән чыккач, кайтып сыеныр куыш тапмаган. Без, Борһан Шәһиди урамында урнашкан приютка барып, анда көн күрүчеләр белән аралашып кайттык.

Биредә урнашкан вагоннарда 40 кеше яши. Әлегә 20се буш тора. Салкыннар башлану белән урын җитми дә икән әле. Анна Макитюкның өеннән чыгып киткәненә 20 елдан артык вакыт узган инде. Ирем аркасында чыгып киттем, ди ул.

– Кыйнады. Рәхәт күрсәтмәде. Өч балабыз бар иде. Ул чакта аларның олысына – 11, кечесенә 8 яшь иде. Кайчан да булса әниләрен эзләрләр әле дип көттем. Тик булмады. Мин аларга кирәк булмаганмын икән, – ди ул, бераз үпкәсен белдереп. – Украинадан мин. Өйдән чыгып киткәч, башта Дагыстанда, аннан Чечняда эшләдем. Бер җирдән икенчесенә йөрдем. Самарада да яшәдем. Аннары эш эзләп, Казанга килдем. Бер белдерү күрдем дә, шул оешмага килеп эләктем. Бер көнгә 200–300 сум вәгъдә иттеләр. Нәрсәгә җитсен соң ул? Әле анысын да түләмәделәр. Ярый бу приют турында ишеттем. 2 айдан артык инде җаным тыныч, торыр җирем бар.

Анна да, күршесе Наталия дә, эштән курыкмыйбыз, диләр. Наталия – Арчаныкы. Ире үлгән, йортында ике кызы яши.

– Арчага көн саен кайтып йөрер өчен дә акча кирәк. Монда ичмасам, эш бар, ашаталар, йокларга урын бирәләр. Миңа приют бик ошый. Өйдә зарыгып көтеп торучы булмагач, монда яшәүнең мең өлеш артык икәненә төшендем. Җитәкчеләргә рәхмәт. Кер дә юабыз, мунча да ягып бирәләр. Нәрсә кисәң шул бар, – ди ул.

Кием дигәннән, бирегә Казанның кайсы гына почмагыннан китермиләр аны. Без булганда да, өч машина килеп, капчык-капчык кием бушатып китте.

– Халык ярдәмчел. Ризыклар да китерәләр, киемнәр дә күп. Хәтта 7 бала караваты да бар. Кирәк кеше үзенә кием алып китә ала. Иң элек үзебездә яшәүчеләрне киендерәбез. Аннары инде калган кешеләргә өләшәбез, – ди приют хезмәткәре Ислам Галиуллин.

Безгә приютны күрсәтеп, анда яшәүчеләр белән таныштырып йөргән Илдарны башта биредә эшләүче хезмәткәрдер дип уйладык. Яхшы итеп киенгән, телефонын кулыннан төшерми. Баксаң, үзе дә шушында яши икән. Йорты янгач, сыену урынын приютта тапкан. Ул да, аның белән бер вагонда көн күрүче Геннадий да – Әфган сугышын кичкән кешеләр.

– Хатыным үлгәч, улыма кирәгем калмады. Куды да чыгарды ул мине. Йөрәк

vk.com

Азат Гайнетдинов әйтүенчә, Казанда мохтаҗлар өчен тулай торак төзеләчәк.

әрни, бик тә борчылам. Улымның кайчан да булса акылына килүен, мине эзләп табуын көтәм. Инде шактый гомер узды, әмма өмет барыбер өзелми, – ди Геннадий.

Илдар белән Геннадий үз бүлмәләрен «комфорт» дип бәяли. Баксаң, килеп керүгә үк яхшы бүлмәгә эләкмисең икән. Бер атна 1 нче вагонда яшиләр. Биредә ятарга урын, чәй эчәргә өстәл бар. Баштарак кешене сыныйлар, эшкә, башкаларга мөнәсәбәтен тикшерәләр, тәртибен карыйлар.

– Урамнан килеп кергән кешене табиблар тикшерә. Аннары алар белән психологлар, юристлар эшли башлый.

Сан

Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәгенең барыр урыны булмаган кешеләр өчен арендалап торган **6** фатиры, **60** урынлы приюты бар. Үзәк Казанның **6** урамында көн саен **1000** кешегә кайнар ризык тарата.

Күбесенең документы юк. Ул мәсьәләне хәл итәргә тырышабыз. Документлары булгач, аларны эшкә урнаштырабыз. Күбесе үз көнен үзе күрә башлый. Шулай итеп, торак мәсьәләсен үзләре дә хәл итә ала, – дип сөйли приют хезмәткәре Ислам Галиуллин.

Казанның Отар бистәсеннән килгән Альберт абыйга – 59 яшь. Ул бер тапкыр да өйләнеп карамаган. Яшьрәк чакта читкә йөреп эшләгән, Үзбәкстанга кадәр барып җиткән. Йөри торгач, паспортыннан колак кага: эшләгән урынында алып калалар да бирмиләр. Әнисе үлеп киткәч, аңа эш урыныннан бирелгән фатирдан да чыгарга туры килә. Шулай итеп, Альберт абый урамда кала.

– Җырлар тыңларга яратам. Өйдән алып килгән радио бар. Әлегә эшем юк. Паспорт алып бирәчәкләр. Тик утырасым килми, эшкә керермен дип торам. Начар гадәтләрем юк. Үзем дә эчмим, эчкән кешене дә яратмыйм. Берәр хатынга ир кирәк түгел микән? Бик теләп, янына китәр идем, – ди ул.

Эчү дигәннән, приютта андыйларны тотмыйлар да. Таләпләре шундый. Биредә хәмер белән дус кешегә урын юк.

Приюттагылар үзләрен кайгырткан өчен җитәкчеләре Азат Гайнетдиновка рәхмәтле. Әгәр ул булмаса, нишләр идек, диләр. Инде хәбәр иткәнебезчә, башкарган эшләре өчен коммерцияле булмаган тернәкләндерү һәм адаптация үзәге җитәкчесе Азат Гайнетдинов күптән түгел республиканың гражданлык җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Президенты премиясенә ия булды.

– Ике ел элек бу премияне безнең оешмага биргәннәр иде. Без ул акчага кешеләрне эшкә урнаштыру үзәге булдырдык. Быелгысы шәхсән үземә тапшырылды. Болай итеп зурлауны көтмәгән идем. Эшемне күргән өчен Президент Рөстәм Миңнехановка чиксез рәхмәт. Ул безгә һәрдаим ярдәм итеп тора. Сукбайларны яшәтер өчен яңа бина да бирде. Әлегә анда төзекләндерү эшләре бара, – ди ул.

Яңа бинада тулай торак булачак. Анда 80 кешене урнаштырмакчылар.

– Араларында төрле кешеләр бар. Кеше хәмер белән мавыга икән, андыйларны бушлай дәвалыйбыз. Авыруларны хастаханәләргә салабыз. Әле менә барысын да паспортлы итеп, коронавирустан вакцина ясатачакбыз. Сукбайлыкта йөргән кешегә башкача да яшәп булганны күрсәтәбез. Аңлау-аңламау исә үзләреннән тора.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

«Мондагы тәртипне саклау җиңел түгел», – ди Ислам Галиуллин.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Приюттагы кешеләрне тыңлый башлагач, барысына – бер язмыш, диясең.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар комитеты рәисе урынбасары **Нугаев** Камил Әсгать улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының Казан нотариаль округы нотариусы, «Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе әгъзасы **Әскәрова** Фәридә Рәүф кызына; Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Гыйниятуллина** Фәридә Илсур кызына; Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Губин** Николай Александровичка; «Татарстан Республикасы Адвокатлар коллегиясе» дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган оешмасының Казан шәһәре Вахитов районы буенча филиалы адвокаты, «Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе әгъзасы **Саматов** Хәмит Хадый улына; Казан гарнизон хәрби суды судьясы **Сердитый** Эдуард Александровичка; «СОЦИАЛЬ БЕЛЕМ АКАДЕМИЯСЕ» автоном коммерциячел булмаган югары белем бирү оешмасының җинаять эшләре процессы кафедрасы мөдире **Сәлимҗанова** Резеда Рәшит кызына; «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе юридик факультетының җинаятькә каршы көрәшү хокукы кафедрасы мөдире, «Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе әгъзасы **Талан** Мария Вячеславовнага; Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Түбән Новгород өлкәсе буенча тикшерү идарәсе криминалистика бүлеге җитәкчесе, юстиция майоры **Карасев** Сергей Николаевичка **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Белдерү

Кадастровым инженером Мубаракшиным Рамилем Наиловичем (адрес: 422060, РТ, Сабинский район, пгт Богатые Сабы, ул. Строителей, д. 4, помещение 1, тел.: (927) 442-67-78, e-mail: ramil40@yandex.ru, квалификационный аттестат 16-11-289) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:33:000000:209, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Пестречинский муниципальный район, Шалинское сельское поселение подготовлен проект межевания земельного участка.

Заказчиком проекта межевания земельного участка является Сафина Альбина Ахатовна (РТ, Пестречинский район, с. Шали, ул. Советская, д. 21; тел.: +7(917)2668988).

С проектом межевания земельного участка можно ознакомиться ежедневно с 8.00 до 17.00 ч. по адресу: РТ, Сабинский район, пгт Богатые Сабы, ул. Строителей, д. 4, помещение 1 в течение 30 календарных дней со дня опубликования данного извещения.

В соответствии с Федеральным законом от 29.12.2010 г. № 435-ФЗ «Об обороте земель сельскохозяйственного назначения» возражения относительно размера и местоположения границ, выделяемых в счёт земельных долей земельных участков должны содержать фамилию, имя и отчество лица, выдвинувшего эти возражения, реквизиты документа, удостоверяющего личность, обоснование причин его несогласия с предложенным размером и местоположением границ выделяемых в счёт земельных долей, кадастровый номер исходного земельного участка. К этим возражениям должны быть приложены копии документов, подтверждающих права лица, выдвинувшего эти возражения, на земельную долю в исходном земельном участке.

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счёт земельных долей земельного участка принимаются в письменном виде либо почтовым отправлением в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения по адресу: 422060, РТ, Сабинский район, пгт Богатые Сабы, ул. Строителей, д. 4, помещение 1.

ИЗВЕЩЕНИЕ О НЕОБХОДИМОСТИ СОГЛАСОВАНИЯ ПРОЕКТА МЕЖЕВАНИЯ

Кадастровым инженером Самоховым Александром Сергеевичем (420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005; 6238322@mail.ru; тел.: 89178883476, № квалификационного аттестата 16-12-546) подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельных долей из земельного участка с кадастровым номером 16:34:000000:296, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Рыбно-Слободский муниципальный район, территория паевого фонда СХК «Чукай». Заказчиком кадастровых работ является Залялов Алмаз Марсович (422650, РТ, Рыбно-Слободский район, пгт Рыбная Слобода, ул. Некрасова, д. 33, тел.: 89274129400). С проектом межевания можно ознакомиться с понедельника по пятницу с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: 420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005, тел.: 89178883476. При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок. Обоснованные возражения и предложения по доработке проекта межевания принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения по адресу: 420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005.

ГӨЛИНӘ ГАЛИМБӘКОВА:

«Татар телен интернетта да саклап була»

Теләче районының Иске Җөри авылында яшәүче Гөлинә Галимбәкова «Инстаграм» сәхифәсен саф татар телендә алып бара. Ул языла лучыларына татар дөньясында, әдәбиятта булган яңалыкларны җиткерә, төрле бәйге, уеннар оештыра.

Белгечлеге буенча математика укытучысы ул. Мәктәптә дүрт ел белем биргән. Укытучылык эшеннән китеп, үз крестьян хуҗалыкларын булдырганнар. Бүген мал асрау белән шөгыльләнәләр. Декрет ялындагы Гөлинә ике ул тәрбияли.

– Мәктәптә укыганда журналистика түгәрәгенә йөрдем. «Алтын каләм» бәйгесендә җиңеп, теплоходларда йөреп кайткан идем. Тик вузга математика юнәлеше буенча укырга кердем. Хәзер дә шигырьләр, хикәяләр язгалыйм, – дип сөйли Гөлинә Галимбәкова.

Гөлинә әйтүенчә, университетта укыганда, иптәшләре телне вата-җимерә сөйләшкәндә яки русча аралашканда, туган телдә сөйләшмәгәнгә кисәтү ясый торган булган. «Гөлинә ачулана бит», – дип, сабакташлары шундук татарчага күчкәннәр. Русча җырлар урынына татар халык җырларын тыңларга кушкан.

– Үзең үрнәк күрсәтеп кенә нәрсәдер үзгәртеп була дип уйлыйм. «Инстаграм» сәхифәсенә озак теркәлмичә йөрдем. Теркәлгәч, нинди юнәлештә эшләргә, дип баш вата башладым. Татар теле, әдипләр турында язам. Узган ел «Татар сүзе» бәйгесенә Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары» әсәрен төшердек. Аны «Инстаграм»да да бик җылы кабул иттеләр. Кешегә әдәби мәйдан һәм видеоформат кирәк икән. Үземнең шигырьләр укыганымны төшерәм, хикәядән өзекләр укыйм. Күптән түгел балалар өчен «Нәни марафон» башладым. Ул ун биремнән тора. Әйтик, беренче биремдә Тукайның «Туган авыл» шигыреннән өзекләр китерергә кирәк. Бармак уеннары, тизәйткечләр әйтү кебек төрле биремнәр бар, – ди ул.

Гөлинә татар телен урамда гына түгел, интернетта да саклап була дип саный. «Яшьләрнең күпчелегенең тормышы «Инстаграм»га бәйле. Татар блогерларының сәхифәләрен кызыксынып карыйлар. Блогерларның туган телне саклап калу мөмкинлеге зуррак. Язмаларыма төрле фикерләр калдыралар. Яшьләр газета-журналларга сирәк языла, әмма электрон басмаларны укыган дусларым бик күп. Без күп очракта, проблемаларны җитәкчеләр хәл итәргә тиеш, дип уйлыйбыз. Телне саклап калу мәсьәләсендә җитәкчеләрдән нәрсәдер көтеп ятканчы, үзеңнән, гаиләдән башларга нәрсә комачаулый? Татарча аралашыйк, туган телне бергәләп саклыйк!» – ди оптимист Гөлинә.

Сәрия МИФТАХОВА

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне үткәрeләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ

2 ОНЛАЙН: vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

Сөенечле хәбәр!

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 атнага бер, җомга килә ~~465 сум~~ 404,04 сум

П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә ~~1000,92 сум~~ 859,08 сум

6–16 декабрь көннәрендә ташламалы бәяләр!

Реклама 16+

«ТАТНЕФТЬ» – ХАЛЫКНЫҢ РУХЫ САГЫНДА

Мәдәни мирас

Рухиятебез өчен «Рухият» тырыша. 200дән артык китап – бу әле чик түгел. «Татнефть» җәмгыяте хәйрия фондының «Рухият» программасы чыгарган басмалар турында сүзебез. «Бер китап мең кешене бәхетле итә», – дигән безнең халык. Менә «Татнефть» тә, гомуми тиражы 23 мең булган һәм яңа гына табадан төшкән тагын 10 китап белән меңләгән кешене бәхетле итәргә ниятли.

Укучы гына түгел, бәхетлеләр исәбендә әлеге китапларның авторлары да бар, билгеле. Быел «Рухият» программасы барысы 10 басма – Ризаэддин Фәхретдиннең «Нәсыйхәт» китабы, Гамил Афзалның «Язбикә», Фоат Садриевның «Көлке көлә килә», Гөлчирә Ибәтуллинаның «Сагына бөдрә таллар...», Җәлил поселогындагы картлар һәм инвалидлар интернат-йортында яшәүче Лилия Гәрәеваның «Серләремне айга сөйлим», Александр Дорофеевның «Лесные сказки» җыентыклары, рус телендә иҗат итүче 12 шагыйрәнең әсәрләре тәрҗемә ителгән Индус Сирматовның «Илһамлы кызлар җыры» җыентыгы, шулай ук Әзһәр Шакировның «Халкыбызның кадерле шәхесләре» китабы, «Олег Кульпин. Кистью и сердцем» альбом-каталогы, «Замандашлар» сериясеннән «Адиб Маликов – записки солдата эпохи» мемуарлар китабын тәкъдим итте. Әлеге китапларның язмышлары да алдан язылган. Ел саен «Татнефть» тарафыннан нәшер ителгән басмалар Татарстандагы китапханәләргә, уку йортларына, музейларга, балалар йортларына, картлар йортларына, шулай ук Россия һәм чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә җибәрелә.

Яктылыкка юл сузучы

«Татнефть»нең «Рухият» программасының ел дәвамында башкарган эшләре бу гына түгел, билгеле. Татарстанның мәдәнияте, әдәбияты, сәнгате үсешенә ярдәм итү, сәләтле балаларны ачыклау, сәләтле яшьләргә даими рәвештә ярдәм күрсәтү, мәдәният һәм сәнгать өлкәсе өчен кадрлар әзерләү максатыннан, яшьләрне махсус уку йортларында белем алырга кызыксындыру, моннан тыш, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә бәйгеләр уздыру, алар нәтиҗәләре буенча премияләрне гамәлгә кую һәм тапшыру – «Рухият» каршына максат итеп куелган файдалы гамәлләрнең берничәсе генә әле бу.

Әйтик, 2006 елда «Татнефть» танылган татар шагыйрәсе Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия булдырды. Ел саен Татарстан Язучылар берлегенең алты әгъзасына акчалата премия тапшыралар, шулай ук әдәби эшчәнлектә үзләрен күрсәткән 10 студент әлеге премия стипендиаты була.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Рөстәм Мөхәммәдиев «Татнефть» компаниясенең яшь талантларга аерым игътибар бирүен искәртте.

Бары лаеклыларга гына бирелә торган әдәби премияне юктан гына искә алмадык. «Рухият»тә очраклы китаплар һәм авторлар, гомумән, юк. «Татнефть» канаты астында инде 1997 елдан бирле эшләп килүче әлеге программа басмалары турында әнә шулай диләр. Билгеле бер авторны укучы белән таныштырырга карар кылсалар, аның әсәрләре берничә «иләк»тән уза икән. Бүгенгә кадәр һәрберсе махсус оештырылган экспертлар комиссиясе әгъзалары биргән хәер-фатиха белән генә дөнья күргән.

Китаплар «Шәхесләребез», «Татар шигърияте мәшһүрләре», «Милли җәүһәрләр», «Дебют», «Балалар өчен китаплар» һәм башка серияләрдә тәкъдим ителә. Моннан тыш, алар – буклет, фотоальбомнар, музыкаль һәм энциклопедик әдәбиятка караучы басмаларга да «җан өрүче». 1998 елдан башлап, яңа басмаларны тәкъдим итү тантаналы рәвештә, дәрәҗәле кунаклар һәм язучы-шагыйрьләр катнашында башкарыла.

«Гуманитар проектларга ярдәм өчен зур рәхмәт!»

Быел исә китапларны «Әлмәт» иҗтимагый үзәгендә тәкъдим иттеләр. Чарага чакырылган мәртәбәле кунаклар арасында Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов та бар иде.

– Мин Әлмәткә һәрвакыт зур теләк һәм үзгә бер өмет хисе белән киләм. Сез нефть каласында гына түгел, республика мәдәниятен, тарихын, телләрен саклау һәм үстерү өчен күп эшләр кылына торган көчле шәһәрдә яшисез. «Татнефть» компаниясе әдәбиятның, сәнгатьнең һәм, гомумән, рухи кыйммәтләрнең җәмгыятьтәге ролен яхшы аңлый. Компаниянең генераль директоры Наил Мәгановка гуманитар проектларга ярдәм күрсәткәне өчен зур рәхмәт! Бүген тәкъдим ителгән китапларның исә үз укучысын табуын һәм озын гомерле булуын телик, – дип сөйләде ул.

«Татнефть» җәмгыяте хәйрия фондының «Рухият» программасы нәшир иткән өр-яңа 10 китап.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Президент каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтовның «Татнефть» җәмгыятенең генераль директоры Наил Мәганов исеменә рәхмәт сүзләрен сәхнәдән депутат, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясенең генераль директоры Илшат Әминов җиткерде. «Милли мәдәниятебезне саклау һәм үстерүгә керткән зур хезмәтегез өчен сезгә һәм сез җитәкләгән коллективка рәхмәтемне белдерәм. Мәдәни мирасыбызны халыкка җиткерү, туган телебезне саклауда «Татнефть» хәйрия фондының «Рухият» программасы зур эш башкара. Комиссия белән берлектә тормышка ашырылган проектлар да шул хакта сөйли. Хезмәттәшлегебез алга таба да дәвам итәр дип ышанам. Эшегездә уңышлар юлдаш булсын, фидакарь хезмәтегезнең нәтиҗәләре куандырсын!» – диелгән Рәхмәт хатында.

«Татнефть» компаниясе генераль директорының социаль үсеш буенча урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев сүзләренчә, ел саен уздырылучы әлеге чара, чыннан да, зур әһәмияткә ия.

– Бер елны шушындый тантанага мәрхүм Туфан ага Миңнуллин да килгән иде. Аның әйткән сүзләре әле дә хәтеремдә. «Менә без – язучылар, шагыйрьләрнең китапларын кайда да бастыралар инде. Хәтта эзлисе дә түгел – күп вакыт арттан йөриләр. Ә бит яшьләр читтә кала! Алар шундый талантлыдыр, ә без белми калырга мөмкин. «Татнефть»нең бу эшкә алынуы – бик тә дөрес гамәл», – дигән иде ул. Мин дә аның сүзләре белән тулысынча килешәм, һәм аларны һәрвакыт кабатларга тырышам, – диде ул.

«Китапны күргәч, күзем яшьләр килде...»

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла:

– «Татнефть» хәйрия фондының «Рухият» программасы чын мәгънәсендә зур эшләр башкара. Бәлки, без аларны әле бәяләп бетермибездер. 25 ел эчендә, җиз иләктән уздырып, бөртекләп сайлап, 200дән артык китап нәшер иткән алар. Бу басмалар, әлбәттә, гади китаплар гына түгел. Бу китаплар – безнең татар халкының менталитетын үзгәртергә сәләтле булган, милли үзаңны күтәрә торган әсәрләр. Әле танылырга өлгермәгән, әмма өмет уяткан яшьләргә игътибар булу да куанычлы. Дөрес, алар алдында ниндидер киртәләр бар, дип әйтәсем килми. Без болай да яшьләребезгә һәрьяклап киң юл ачарга тырышабыз, яшел ут кабызабыз. Әмма бу эштә иң беренче нәүбәттә «Рухият» тырыша. Бу эшне ул башлап җибәрде дисәм, бер дә ялгыш булмас. Бәлки, яшь язучы яки шагыйрь бөек әсәр язгандыр. Сез хәерхаһлы булмасагыз, без моны белә дә алмас идек. Шушы еллар эчендә сезнең ярдәм белән татар әдәбиятында горурланырлык исемнәр шактый барлыкка килде, – дип сөйләде.

Чарада китапларның авторлары да катнашты. «Лесные сказки» җыентыгы авторы, Лаешта гомер итүче Александр Дорофеев исә сәхнәдә күз яшьләрен тыя алмады.

– «Лесные сказки» җыентыгының тарихы шактый кызыклы. Мин язучы түгел, шуннан башларга кирәктер. Моннан берничә ел элек оныгыма әкият язып карадым. Урманда яшәүчеләр турында иде ул. Оныгым аны шундый кызыксынып тыңлады! Шуннан мин тагын берничә әкият яздым. Аннан тагын. Ә бүген менә минем әкиятләрдән төзелгән җыентыкны шушындый зур сәхнәдән тәкъдим итәләр. Күзләр ничек яшьләнмәсен инде! – диде ул.

Мәртәбәле кунаклар яңа китапларның үз укучысын табасына һәм озын гомерле буласына ышаныч белдерде.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.

Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7387 данә
Гомуми тираж – 17167 данә

Газетага сертификат бирелде. Заказ 377

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт. График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+

ЙОМРЫ ГӘҮДӘЛЕ...

БӘРӘҢГЕ

Кабыклы килеш пешерелгән бәрәңгедә клетчатка банан-
га караганда биш тапкыр күбрәк туплана. Димәк, андый бәрәңге эчне катырмый, киресенчә, эч кипкәннән ярдәм итә һәм токсиннарны чыгара дигән сүз. Ул шулай ук холестеринны киметә, кандагы шикәр күләмен көйли.

Чикмәнле бәрәңге – С витамины чыганагы. Ул тимерне үзләштерергә ярдәм итә, кан тамырларына уңай йогынты ясый, вируслардан, инфекцияле авырулардан коткара. С витамины – көчле антиоксидант, ул ирекле радикалларга каршы көрәшә, организмның вакытыннан алда картаюын булдырмый.

Моннан тыш, кабыгында пешкән бәрәңгедәге селен матдәсе чикләвек һәм көнбагышка караганда күбрәк. Башка бер генә ризыкта да моның кадәр селен юк. Ул иммунитетны һәм нерв системасын ныгыта, организмның авыруларга каршы тору үзлеген арттыра, матдәләр алмашын яхшырта. Тән тиресе, чәч, тырнакларны матурайта.

Әгәр кабыклы бәрәңгене суда пешерәсез икән, аны түгәргә ашыкмагыз. Ул майларны яндыра, артриттан коткара, йөрәк авырулары һәм гипертониядән ярдәм итә.

БӘРӘҢГЕ СОГЫ

vk.com

Бәрәңге согында иммунитетны яхшырта торган С витамины бар. Икегә аерылган юка чәчләрне шулай ук бәрәңге согы белән дәвалыйлар. Аны чәч төбенә сылап, 20 минут тотыгыз да юып төшерегез. Коры бит тиресен мамыкка манылган бәрәңге согы белән дымландырыгыз. Бәрәңге согы йөрәк өчен дә файдалы, ул холестерин күләмен киметә. Гастрит вакытында бәрәңге согын ун көн эчеп, ун көн тәнәфес ясарга кирәк. Иртән ашарга ярты сәгать кала аны бер стакан эчәргә кирәк. Бәрәңге согы бавырны һәм үт куыгын агулы матдәләрдән чистарта. Аны еш эчкәндә, ашказаны-эчәк тракты эшчәнлеге яхшыра.



Нияз Бишбалта

Сәламәтлек

Остеоартроз

Буын кимерчәгенең һәм аны каплап торучы юка сөяк катламының башалуы остеоартроз дип атала. Ул күбрәк тез һәм бот буыннарын зарарлый. Остеоартроз буын сөяге, кимерчәк, бәйләвеч, сеңер, мускуллардагы үзгәрешләр, буын мае кибү, ян-яктан сөякләрнең үсеп китүе (кылчыклар хасил булу), буынның ялкынсынуы, анда су җыелу, шешү һ.б. нәтиҗәсендә барлыкка килә. Әлеге авыру күбрәк илле яшьтән узган кешеләрдә күзәтелә, чөнки олыгайган саен организмдагы күзәнәкләр дә «картая». Кимерчәкнең ашалу процессы күзәнәкләрнең яңаруына караганда тизрәк бара.

Коксартроз

Буын зарарланганда, башта ул кыска вакыт эчендә сызлап, авыртып ала. Кеше аңа игътибар бирмәскә дә мөмкин. Авырту көч килгәндә, бер халәттә озак торганда арта. Утыргач, бераз ял иткәч, авырту бетә һәм кеше шуның белән алдана. Тора-бара авырту ял иткәч тә узмый, буыннар төнлә дә сызлый башлый.

Остеоартроз чиренең тагын бер билгесе: иртәнгә буыннар ката. Буыннарның майланмаган тәгәрмәч кебек шыгырдавы да остеоартроз авыруы барлыгын күрсәтә. Авыру азган саен, буынның формасы үзгәрә, ул урыныннан күчә, бер якка авыша, зурая.

Остеоартрозны дәвалауны мөмкин кадәр иртәрәк башларга кирәк һәм ул комплекслы булырга тиеш.

БУЫННАРНЫ НИЧЕК САКЛАРГА?

Аягөсте озак тору, аякларның берсен икенчесе өстенә куеп утыру зыянлы. Биек үкчәле аяк киеменнән баш тарту, биек аркалы утыргычка утыру мөһим. Кайберәүләр, буыннарны язабыз дип, баскычтан җәяү менә, төшә. Бу шулай ук зыянлы. Утырып эшләгәндә аякларны селкетеп алу яки пластик шешәгә су тутырып, шуны тәгәрәтү файдалы. Остеоартроз белән авырганда, чама хисен онытмыйча, спорт белән шөгыльләнергә, йөзәргә мөмкин. Туклануга игътибар итәргә, артык гәүдә авырлыгын киметергә кирәк.

Тәмле булсын!

Балан бәлеше

Кирәкле ингредиентлар: 400 грамм әче камыр. Эчлек өчен: 600 грамм балан, 80 грамм куас оны, 250–300 грамм шикәр комы, 150–200 грамм атланмай.

Баланны, чүбеннән аралап, тирән эчле, калын төпле савытка салабыз. Аз гына су, куас оны, шикәр комы кушып, пешереп алабыз. Әче камырны ике кисәккә бүлеп, зуррак өлешен җәябез дә майланган табага салабыз. Өстенә суынган балан эчлеген салып, аңа шикәр комы, атланмай өстибез. Икенче өлеш камырны җәйгәннән соң, өстенә ябып, читләрен тоташтырып, бөреп куябыз һәм, өстенә йомырка сарысы сөртеп, валчык сибәбез. 180°С кызулыктагы мичтә 40–45 минут пешерәбез.

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ
Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы һәм «Ватаным Татарстан» газетасының уртак кушымтасы.
Чыгарылыш өчен җаваплы – **Гөлгенә ШИҺАПОВА**. Биткә салучы һәм бизәүче – **Рөстәм МИҢНУЛЛИН.**
Безнең адрес: Казан шәһәре, Театр урамы, 13 й.
Телефон: 8(843) 238-16-88
Электрон адрес: soovp.kzn@tatar.ru

ҖИР КЕШЕСЕ

> 4

ЭШ ОСТАСЫ

> 6

ФОТО-МИЗГЕЛЛӘР

> 8

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ

РЕСПУБЛИКА ВЕТЕРАННАРЫ (ПЕНСИОНЕРЛАРЫ) ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ СОВЕТЫ ҺӘМ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ УРТАК КУШЫМТАСЫ

№ 11-12 | Шимбә | 4 декабрь | 2021 ел

50 ЕЛ БЕРГӘ ЯШӘҮЧЕ ПАР:

«БЕЗНЕ ХӘСРӘТ ТАГЫН ДА ЯКЫНАЙТТЫ»

Түбән Чәке авылында яшәүче Рузания апа белән Шамил абый Мөбиновларның бергә гомер итүләренә – 50 ел. Үзләре әйтүенчә, әлеге вакыт сизелми дә узып киткән. Артка карасаң, сагынып сөйләрлек сүзләре күп аларның.

Шамил абый – искиткеч киң күңелле, иҗади кеше. Гомер буе хезмәт итеп, хәзерге көндә дә үз тормышын гармун, тальяннардан башка күз алдына китермәгән, алай гына түгел, аларга икенче «гомер» бүләк итүче оста да ул. Тормыш иптәше Рузания апа авыл халкы сәламәтлеге сагында дүрт дистә елга якын хезмәт куйган.

Моннан 50 ел элек танышулары, кавышулары да кызык кына булган аларның. Алар икесе дә бер сыйныфта белем алалар.

– Мәктәптә укыганда үз сыйныфташыңа кая инде ул игътибар бирү: күзләр чит-ятларны күзли иде, – дип искә ала Шамил абый. Шуңа күрәдер инде, алар арасында да мәхәббәт хисләре соңрак, мәктәпне тәмамлап, авылга белем алып кайткан белгечләр булгач кына кабына.

Рузания апа Буада медицина училищесында укый. Шамил абый исә армия хезмәтеннән соң колхозга кайтып, шофер булып урнаша. Рузания апаны башта Яңа Кәкерле авылына шәфкать туташы итеп билгелиләр.

> 2

Юбиляр

Күңелең нинди – гомерең шундый

Апас районының Дәүләки авылында яшәүче Сарибә Тимербулатовага 90 яшь тулды. Туган көне уңаеннан котлау һәм бүләкләргә күмделәр аны. Үзен котларга килгәч, әбекәй хезмәт һәм гомер юлын барлады.

– Эштән курыкмадым мин, – диде ул кунакларга. – Безнең чорга хезмәтнең дә авыры туры килде. Әткәйдән 5 бала калдык. Капка төбендә елашып озатканыбыз исемдә саклана. Шуннан соң бик кыенлык белән үстек. Әти сугыштан кайтмады. Ачлыгы да, ялангачлыгы да башыбыздан узды инде. Үлән, черек бәрәңге ашап үстек без. Тамак туйдырыр өчен күп тырышырга туры килде.

Сарибә әби 10 яшеннән эшли башлый. Яшелчә үстерүдә дә, кырчылыкта да эшли ул. Бик күпләр аны Дәүләкинең оста пешекчесе буларак та исендә калдыргандыр. Озак еллар ашханәдә хезмәт иткән. Әбекәйнең ризыкларын авылда ашап карамаган кеше калмагандыр, мөгаен. Шул ук вакытта колхоз эшләрендә катнашкан. Гектар-гектар чөгендер эшкәртү дә эләккән аңа. Яшьлеге авырлык белән узса да, алдагы тормышы бәхетле була аның. Ул – бик бәхетле ана. 4 кызы да әни дип өзелеп тора. 8 онык, 14 оныкчыгы дәү әниләрен хөрмәтләп яши.

– Хәзер тормышыбыз шөкер итәрлек. Тәрбиядә яшим. Ирем Бөек Ватан сугышы ветераны иде. Бик әйбәт гомер иттек. Бабам исән түгел инде. Олы кызым Рузия тәрбиясендә гомер итәм, – ди Сарибә әби.

Озын гомерле булуның серен яхшы күңел белән яшәүдә күрә Сарибә әби. Бүген дә бөтен кешегә изге теләктә яши, догасыннан калдырмый.

– Әнкәй тормышны, янәшәсендәге кешеләрне яратып яши. Әти белән әни безнең өчен дә, башкаларга да үрнәк гаилә булдылар. Кадерләп кенә үстерделәр, – ди кызлары Рузия белән Наилә.

Ләйлә ШИҺАБИЕВА.
Апас

КИТАПХАНӘЧЕ СӨЕМБИКӘ АПА

Бөек Ватан сугышы ветеранының тол хатыны, тыл ветераны, Иске Рәҗәп авылында гомер итүче Сөембикә Ханиева 95 яшьлек олы юбилеен билгеләп үтте. Сөембикә апа озак еллар мәктәбебездә китапханәче булып эшләде. Гади китапханәче!

Гадилеккә пөхтәлек тә, чисталык та, осталык та кергәнен белсәм дә, гади дию белән килешә алмыйм мин. Мәдәният, белем, яктылык, матурлык таратучы итеп карыйм. Китапханәче хезмәте – күзгә күренми торган гаять дәрәҗәдә авыр, ләкин мактаулы эш. Үз эшен чын күңелдән бирелеп башкарган Сөембикә апага мин гомерем буена рәхмәт әйтеп яшим, минем остазым, дип әйтсәм дә, ялгыш булмас. Ул безне китап укырга өйрәтте. Китапханәчебездән мактау сүзе ишетү өчен күпме шигырьләр ятладык без! Урыс классикларының татарчага тәрҗемә ителгән хәйран гына әсәрләрен дә укырга насыйп булды. Хәзерге кебек фестивальләр дә үткәрелмәгән, призлар да бирелмәгән бит ул чакта. Сөембикә апа әтигә әйтеп (әтием Әхмәт Алишев мәктәптә укытучы) мактый иде бит. Ничек өйрәнмисең, укымыйсың ди! Апабыз китап укучыларны үзенчә төркемнәргә дә бүлеп куя иде. Сүлпән укучыларга – юкарак, тизрәк укый алучыларга калынрак китапларны бирә. Үзе: «Менә бу китап шул хакта икән, укып чык әле, эчтәлеген миңа да сөйләрсең, бик беләсем килә», – дип искәртеп тә куя.

Тормыш иптәше Кадыйр абыйны эшкә озатып каршы алу, каенанасы Минзада әбине, дүрт баланы карау эшләре белән Сөембикә апабызның китап укырга вакыты да калмаганын беләбез. Шуңа күрә «үтенеч»ен бик рәхәтләнеп үтәргә тырыша идек.

... Мин үзем кечкенәдән китаплар яраттым. Китапханәгә еш йөрдем. Кулыма китап алгач та тиз генә өйгә кайтырга ашыкмыйм. Стеллажлардагы китап киштәләренә текәлеп карап торам да торам. Шул китап киштәләрендәге китаплар арасында ниндидер сер яшеренгән, могҗиза бардыр дип уйлый идем. Һәрбер китапны кулыма тотып карыйсым килә иде. Сөембикә апаның мөлаем сөйләшүенә, таләпчән һәм бик хәрәкәтчән булуына соклана идем.

– Их, китапханәче булып, шул китаплар арасына кереп чумсам икән, дип хыяллана идем. Әйе, китапханәче булып авылыбыз китапханәсендә 43 ел эшләдем мин. Сөембикә апа миндә бу һөнәргә мәхәббәт тәрбияләде.

Гомер еллары сизелми дә үтә тора. Җимертеп эшләгән чаклар да күптән артта калган. Сөембикә апабызга 95 яшь тә тулган. Тырыш, уңган, ачык күңелле апабыз туган авылында кече улы Ришат гаиләсе белән бергә яши. Читтәге балалары Роза, Дания, Ринат гаиләләре әниләре янында еш кунак булалар. Юбилей көнне дә алар зур, мул табын янына җыелдылар. Һәрберсе үзләренең рәхмәтләрен ирештерергә тырышты.

Авылыбыз башлыгы Мансур Нугаев юбилярга авыл җирлеге советы, Россия Президенты Владимир Путин һәм район башлыгы Фәргать Мөхәммәтов исеменнән котлаулар ирештерде, бүләкләр тапшырды. Шулай ук авылыбызның ветераннар (пенсионерлар) советы һәм мәдәният йорты хезмәткәрләре дә юбилярга матур теләкләр теләде.

Сөембикә апа дөнья хәлләре белән танышырга, газеталар укырга ярата. Ул киләсе ел өчен район газетасы «Яңа тормыш» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарына язылып та куйган инде.

Флёра ХӘЙРЕТДИНОВА.
Спас районы

Сиксән елдан соң кайту

Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 76 ел гомер үтте. Ә аның кайтавазы әле һаман яши. Сугыш мәхшәре күрсәткән авырлыклар, туган илебезнең азатлыгын каһарманнарча яклап яу кырында гомерләрен биргән геройларыбыз, фашистларны җиңеп кайтып, җимерек илебезне өр-яңадан торгызып, хезмәт батырлыклары күрсәтеп, үзләренә лаеклы алмаш үстереп, бакыйлыкка күчкән авылдашлар, хәбәрсез югалганнар истәлеге буыннан-буынга күчеп яши.

Әле менә быел язгы айларда сөенечле хәбәр килеп төште авылга – 1942 елда Смоленск тирәсендә барган сугышларда Вязьма җирендә ятып калган, ә өенә «хәбәрсез югалды» дигән хат килгән Әхкыяметдин Камалетдиновның җәсәде һәм шәхси әйберләрен Смоленск шәһәренең «Эхо» эзтабарлар отряды эзләүчеләре тапкан. 80 елга якын җир астында яткан газиз истәлекләрне Түбән Каманың «Нефтехимик» эзтабарлар отрядына тапшырганнар. Билгеле сәбәпләр аркасында экспедиция әлеге табышны туган авылына шушы көннәрдә генә китереп җиткерде.

Истәлекле әйберләрне кызы Нуриягә тапшыруга багышланган очрашуны авылның мәдәният йортында үткәрдек. Геройның кызы Нурия апа Гыймазиева әтисе сугышка чыгып киткәндә әнисенең карынында калган. Бер тапкыр да әти сүзе әйтә алмыйча гомер иткән.

Ахыры 4 нче биттә >

50 ЕЛ БЕРГӘ ЯШӘҮЧЕ ПАР:

«Безне хәсрәт тагын да якынайтты»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Анда барыр өчен һәр көн юлга чыгасы була, ә авылдан ул заманда колхоз машиналары гына йөреп тора. Шофер егет Шамил сыйныфташын үз машинасына утырта, билгеле. Тора-бара кыз башкаларга утырып китмәсен өчен төрле җаен да күрә башлый. Мондый игътибарны тойган Рузания үз авылларына фельдшер-акушерлык пунктына эшкә күчкәч тә, авырулар янына барырга, йә булмаса авыруны районга илтергә кирәк булганда әлеге шофер сыйныфташына мөрәҗәгать итә башлый. Яшьләр дуслыкның мәхәббәткә әверелүен сизми дә калалар. Бер-берсен озак күрмичә тора алмауларын төшенгәч, өйләнешергә сүз куешалар.

– Шамилне яратмау мөмкин дә түгел иде. Ул колхоз эшеннән тыш, авыл клубында спектакль, концертларда катнашып йөрде. Сәхнә түреннән төшмәде дә, – ди Рузания апа, яшьлек хатирәләрен яңартып.

Рузаниясен алып кайтырга сөйләшкән кичне дә ул сәхнәдә театр уйный әле.

– Карасам, Рузаниям залда юк, спектакль әле бетмәгән, ә ул кайтып киткән. Ни дияргә дә белмим, ролемнең сүзләрен оныттым. Кире уйлады, ахры, инде бу, миңа кияүгә чыкмаска булды, дигән уй килде башка. Спектакль бетүгә үк таныш дустым һәм аның йөргән кызы белән Рузанияләргә киттек. Бер әбинең хәле бик начар дип, өеннән чакырып чыгардык. Безнең өйгә кайтырга чыктык. Шулвакыт авыл халкы чабышырга тотынды. Нәрсә булды икән дисәк, тегермән яна. Кайсы – чиләк, кайсы – бау, кайсы көрәк тотып чаба. Өйгә соң гына кайтып җиттек. Дустым да кызын шул кичне өенә алып кайткан булып чыкты, – дип көлеп искә алды ул көннәрне Шамил абый.

Икенче көнне эшкә баргач, егетләргә колхоз рәисе: «Бөтен авылны яндыра яздыгыз бит, берьюлы икәүләшеп өйләнмәсәгез дә була иде инде», – дип шаярта.

Әнә шулай башланып китә аларның тормышы. Төп нигездә Шамил абыйдан кала, тагын биш бала була. Бераз бергә яшәгәннән соң, алар өй җиткезеп чыгалар. Гаиләдә бербер артлы ике кыз бала туа.

– Мин медпунктта эшли башлаганда авылда 500дән артык бала бар иде. Юллар, заманча биналар юк. Шулай да эшләдек, зарланмадык. Көн димәдем, төн димәдем – авыру янына чакыру булуга барып җиттем, – ди Рузания апа.

Бу гаилә бала хәсрәте дә кичерә. Олы кызлары 21 яшендә фаҗигале төстә вафат була. «Әлеге кайгыдан соң без тагын да бербөтен булып яши башладык», – ди Рузания апа.

Икенче кызлары Гөлназ үз гаиләсе белән районда яши. Тормыш иптәше Рафаэль белән өч бала үстерәләр. Әби-бабалары аларның уңышларына куанып, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтле булып гомер кичерәләр. Тынгысызлар үзләре. Шамил абый үзенең гармуннар коллекциясе, аларда сыздырып уйнавы белән мәдәният өлкәсендә хезмәтен дәвам итсә, Рузания апа хәзер кешеләрнең күңелен дини юнәлештә, әхлакый тәрбия, гыйлем бирү белән дәвалый.

– Тормыш башлаган яшь парларга киңәш итеп, гаилә шатлыкны да, кайгыны да бер булып, сабырлык белән кичерергә тиеш, диясем килә. Гомер сизелми үтә дә китә – яшьлекнең, тормышның кадерен белү кирәк. Шул очракта гына гаиләдә бәхетле буласың, – ди алар.

Гөлия ФӘИЗОВА.
Чүпрәле

ӨЛКӘННӘР ТОРМЫШНЫ ЯРАТА

Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк оешмасының рәисе итеп яңадан Хәбир Иштирәков сайланды. 12 ноябрь көнне ветераннар оешмасы 5 еллык эшчәнлегенә хисап ясады. Хисап-сайлау җыелышыннан фоторепортаж тәкъдим итәбез.

ЭШНЕ ЯРАТЫРГА КИРӘК

Апас районының Олы Болгаер авылында яшәүче Юлия Заһретдинованың нинди генә шөгыльләре юк. Кечкенә генә гәүдәле, җитезлеге, тапкырлыгы белән шаккатырган ханым мең төрле һөнәре белән мактана ала. Бакчасыннан мул уңыш ала. Һәвәскәр бакчачының үзе генә белгән серләре шактый. Өендә яратып гөлләр үстерә. Кул эшләренә дә оста. Йон оекбашлар, бияләй, башмаклар бәйли. Юлия апа кече яшьтән үк спортны да үз итә. Чаңгыда йөгереп, бәйгеләрдә җиңүләр яулый, урыннар ала.

«ТУФРАК ӨШЕРГӘ ТИЕШ»

Юлия Заһретдинова бакчачылык кәсебе белән дә күптәннән һәм яратып шөгыльләнә.

– Туфрак – югары, мул уңыш алуның төп нигезе. Иң элек аны орлыкларны чәчәр алдыннан барлык шартын китереп әзерлим. Көз көне үк туфракны казып алам. Аны билгеле бер урынга куеп, кар астында өшергә калдырам. Туфрак өшергә тиеш. Аннан чәчәргә вакыт җиткәндә алып кереп эретәм. Туфракны җылыткач, иләк аша чыгарам. Бу вакытта барлык чүп-чарлар да савытка керми кала, – ди һәвәскәр бакчачы.

Юлия апа инде борыч үсентеләрен күчереп утырткан. Помидорлар исә яңа тишелеп чыккан. Помидорны үстерүнең дә үз серләре бар.

– Узган ел тәҗрибә үткәреп карадым. Үсентеләрне өйдән парникка чыгармадым. 1 май көнне ачык җиргә 17 төп оя ясап, төп саен берәр чиләк кайнар су салдым. Оя суынгач, помидорларны утырттым һәм, таяк бәйләп, тукыма белән каплап куйдым. Ике башын томаладым. 2 атна дәвамында ачмадым. Бу вакытта помидорларым зур булып үсеп куйганнар иде. Иртә өлгерде, уңышы күп булды, авырмады да. Үсентеләр бит күчергән саен чирли. Быел да шулай эшләргә исәбем, – ди ул.

Юлия апа яшелчәләрне муллан үстерә. Кабаклары мул уңыш бирә, карбызлары баллы булып өлгерә. Кишер, чөгендер, суган, кәбестә, ташкабак, патиссон һәм башкалар да кимен куймый.

– Карбыз үсентеләрен өйдә үстермим. Орлыкны май башында җиргә чәчеп, пленка белән каплыйм. Күчереп утыртканда төп саен ком салып калдырам. Карбызлар ел саен өлгерә. Кишер үсентеләрен икенче тапкыр сирәкләгәннән соң, 1 чиләк суга 3 грамм марганцовка һәм 2–3 грамм бор кислотасы салып эреткән катнашманы сибәм. Әлеге катнашма 3–4 квадрат метр мәйданга җитәчәк, – ди Юлия апа.

«Яшелчәләр уңсын өчен нәрсә эшләргә кирәк?» – дигән сорауга: «Карарга, иренмәскә, җир эшен яратырга, вакытында суын сибәргә, чүбен утарга кирәк. Мин үзем ашламалар кулланырга яратмыйм», – дип җавап бирде ул.

Юлия апаның яшелчә үстерү серләре гади һәм сыналган.

– Яшь кычытканнарны, чүп үләннәрне җыеп савытка тутырам, өстенә су салып, озак кына әчетәм. Аннан 2 атна саен помидорларга шул суны сибәм. Суган кабыгы суы да бик файдалы. 3 литрлы банканың яртысына суган кабыгы тутырам, су салам, капкач ябып, 4 көн кояшта тотам. Аннан сөзеп алам һәм 2 атна саен сибәм. Ул помидорларны фитофтородан саклый, – диде ул.

Юлия апаның гөлләре дә шаулап үсә, матур чәчәкләре белән сөендерә. Ул аларны да күңел җылысын биреп үстерә.

«БӘЙЛӘҮДӘН ЛӘЗЗӘТ АЛАМ»

Юлия апа кул эшләренә кечкенәдән өйрәнгән. Үзе белгәннәрне дусларына, танышларына, авылдашларына да өйрәтергә ярата.

– 4 нче класста укыган вакытта ук бәйләргә өйрәндем. Кулларым канап, инәләр бөгелеп бетә иде. 6–7 класста укыганда оекбашлар, бияләйләр бәйли башладым. Балачактан бирле бәйләүдән аерылганым юк, – ди үзе.

Юлия апаның бәйләгән башмаклары белән шкафы тулган. Алар берсен-берсе кабатламаган. Барысы да төрле-төрле. Үрнәкләрне газета-журналлардан да ала, оныклары интернеттан та табып күрсәтә икән. Матур итеп картиналар чигәргә дә ярата, аларны якыннарына бүләк итә.

– Кул эшләреннән ләззәт алам. Бик «тәмле» шөгыль ул. Бу вакытта мин ял итәм, уйларым белән туган якларда, туганнар янында, яшьлек елларымда йөреп кайтам. Бер тотынгач, тизрәк бәйләп бетерәсе килә. Ул эш гел котыртып, үзенә тартып тора, – ди.

«СПОРТ – ДУСТЫМ»

Юлия Заһретдинова тумышы белән Чувашиядән. Уку йортын тәмамлагач, Апас ягына юллама белән эшкә килә. Кияүгә чыгып, Олы Болгаер авылында төпләнеп кала. Ире Минзанур абый белән алар 62 ел бергә матур, тату, үрнәк гомер итәләр. Юлия апа гомере буе авыл халкының сәламәтлеге сагында тора, бик күпләрнең кендек әбисе була, никадәр сабыйга дөньяга килергә ярдәм итә.

Үзе дә сәламәт тормыш рәвеше яклы ул. Балачактан спортны үз итә. Кечкенәдән чаңгыда йөри. Олыгайгач та әле төрле бәйгеләрдә, ярышларда катнаша, җиңүләр яулый. Районкүләм чаңгы ярышларында алган мактау грамоталары да бар.

Юлия апа бүген дә тик утырмый. Бик күпләргә үрнәк булып, моңаймыйча, көр күңелле булып яши.

Ләйлә ШИҺАБИЕВА

Хезмәтенә күрә – хөрмәте

Район ветераннар советы рәисе Миргасим Кәримов шушы көннәрдә Азнакай районының 90 еллыгы уңаеннан 41 ел гомерен мәктәптә балалар укытуга багышлаган Лира Рахманкуловага медаль тапшырды.

Лира ханым педагогик эшчәнлеген моннан 60 ел элек Карамалы авылында башлый. Шушы авылда ул үзенең гомерлек юлдашын – күршедәге Таллы Бүләктә үсеп, Бөгелмәдә механизаторлар мәктәбен тәмамлаган шофер егет Термусны очрата. Бераздан алар өйләнешәләр, гаилә коралар.

Партиянең район комитеты эшкә батыр, җәмәгать тормышында актив булган яшь гаилә башлыгын Казанга авыл хуҗалыгы җитәкчеләре әзерләү курсларына җибәрә. Шунда укыганда Термус Рахманкулов 10 нчы классны тәмамлый һәм авыл хуҗалыгы институтының хисап-икътисад бүлегенә укырга керә. Читтән торып укып, югары белем ала. «Тырыш» колхозында партоешма секретаре, «Кызыл Байрак»та колхоз рәисе, «Бирючевка»да һәм Вахитов исемендәге совхозда директор булып эшли. «Вахитов»та җитәкчелек иткән елларда халыкның тормыш шартларын яхшыртуга зур көч куя. 94 торак йорт, күпсанлы социаль-көнкүреш биналары төзетә. Термус Рахманкуловның тырыш хезмәте «Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» исеменә һәм күп кенә орден-медальләргә лаек була.

Һәр уңышлы кеше артында гадәттә аның ире яки хатыны тора: эшкә чумып, тулысынча бирелеп эшләү, уңышларга ирешү өчен алар шартлар тудыралар, көнкүреш мәшәкатьләрен үз өсләренә алалар. Лира ханым да, ирен кая җибәрсәләр, шунда була. Авыл мәктәпләрендә һәм 28 нче профтехучилищеда тарих, җәмгыять белеме, политэкономия фәннәрен укыта, бала үстерә, өйне карап тота, хуҗалыкны алып бара.

– Лира Рахманкулова тирән белемле, тыйнак, пөхтә, сабыр, искиткеч яхшы укытучы булды. Эшен яратып, намус белән башкарды. Балаларны яратты, ата-аналар аны хөрмәт итте. Өендәге чисталыгы, уңган-булганлыгы әле дә күз алдымда тора, – ди чордашы, Вахитов урта мәктәбендә күп еллар укытучы һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшләгән Расиха Гәрәйшина.

– Улыбыз Айдар Казан авиация институтын, ике оныгыбыз медицина институтын тәмамладылар. Гаиләләре белән Сочи шәһәрендә яшиләр һәм эшлиләр. Термус белән 46 ел матур, бәхетле гомер иттек. Ләкин Аллаһы Тәгаләдән узып булмый, ул 70 яшендә 2008 елда вафат булды.

Лира ханым икетуган сеңлесе Хәнә белән гомер итә. Хәнә гомер буе сәүдә системасында эшләгән. Икесе дә, ирләре вафат булгач, сыңар канатлы калганнар. Икесенең дә уллары яннарында түгел: шалтыратып, хәбәрләшеп, ярдәм итеп торалар. Бер нәселдән булган ике кыз туган, апа-сеңел кебек чөкердәшеп, бер-берсенә терәк, таяныч булып яшиләр. Намаз укыйлар, газеталар аша район, республика яңалыклары белән танышып торалар, гөлләр үстерәләр, Скандинавия таяклары белән көн дә бер-ике тапкыр йөреп кайталар.

Нәсимә КАМАЛИЕВА,
район ветераннар советы әгъзасы.
Азнакай районы

БЕР ЕЛГАНЫҢ ИКЕ ЯРЫ КЕБЕК

Редакция белән типография – бер елганың ике яры кебек. Редакция яза, тәрҗемә итә, халыкка җиткерәсе хәбәрләрне әзерли. Ә типография без язганны газета итеп бастырып чыгара. Бер бинада, бер түбә астында бер гаилә кебек эшләде ике коллектив. Азнакай типографиясе ун ел элек яшәүдән туктаса да, район тарихында аның роле һич кимеми һәм монда эшләгән кешеләрнең хезмәте онытылмый. Искә төшерергә сәбәп тә бар: районыбыз үзенең 90 еллыгын бәйрәм иткән 2021 елда типографиянең дүрт ветераны шәхси юбилеен билгеләп үтә.

1977 елның җәендә мин әдәби хезмәткәр булып редакциягә эшкә килгәндә, Сирина типографиядә ике елдан артык эшләргә өлгергән иде инде. Легендар фотохәбәрче Рифгать Садриевның килене ул. Азнакайның 2 нче урта мәктәбен тәмамлагач, яшьлек романтикасы белән комсомол путевкасы буенча Түбән Кама шәһәрен төзергә киткән. Анда ташчы буларак беренче хезмәт чыныгуын алган. Яңадан 36 ел дәвамында Садриева Сирина Мирхәтим кызы типографиядә тырыш хезмәт куйды. Биш директор чорында эшләде ул. Тираж 15әр мең тәшкил иткән заманнарда төн урталарына кадәр газета басты, кирәк булса, кәгазь кисте, китап төпләде. Газета басучыларның республика конкурсларында катнашып, призлы урын алды, «Һөнәре буенча иң яхшы» исеменә лаек булды, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Мәсгут авылы кызы Гаҗилә дә хезмәт юлын төзелештә башлаган. Ун ел маляр булып эшләгәннән соң килде ул полиграфистлар коллективына. Башлыча китап төпләү цехында эшләде. Типография бит газета басудан тыш төрле заказлар үти, брошюралар, буклетлар чыгара, телефон белешмәләре, амбар китаплары, таныклыклар, кенәгәләр ясый иде. Заказлар бик күп һәм ашыгыч булганда, башкалар да Гаҗиләгә ярдәмгә керде. Ул үзе дә кирәк чакта газета басты, кулы белгәч, бина эчендә буяу, сылау эшләрен дә башкарды. СМУ-29да да, типографиядә дә «Коммунистик хезмәт ударнигы» исемен алды, Мактау грамоталары белән бүләкләнде Мөбарәкшина Гаҗилә Гобәй кызы.

Мачаклыбаш авылы кырыендагы өч өйле кордонда үскән Хәсәншина Эльмира Фәррах кызы полиграфист эшен яшьтән сайлаган. Азнакайның 1 нче урта мәктәбен тәмамлагач, Казанда техник училищеда машина белән хәреф җыючы (линотипистка) һөнәрен үзләштергән ул. Юллама буенча китеп, дүрт ел Түбән Кама шәһәрендәге типографиядә газета чыгаруда эшләгән. Азнакай типографиясенә тәҗрибәле, белемле һөнәр иясе булып 1980 елда килде. Линотипта да эшләде, кул белән хәреф җыю осталыгына да өйрәнде. Бездә 26 ел эшләү дәверендә үзен тырыш, тыйнак, ипле хезмәткәр итеп танытты. Югары хезмәт күрсәткечләренә ирешүе һәм җәмәгать тормышында актив катнашуы өчен район хакимиятенең Мактау грамотасы белән бүләкләнде, рәсеме типографиянең Мактау тактасында торды.

Чыгышлары Сарлы авылыннан булган Зиннәтуллиннар матбугат өлкәсен аеруча үз итте. Мин эшкә килгәндә олы абыйлары Шәһадәт редакциядә – шофер, ә аның сеңлесе Мөнирә типографиядә линотипистка иде. Бераздан «Ленколхозстрой» оешмасында ташчы булып эшләгән Гакифә дә аларга килеп кушылды. Яңадан Гакифәнең улы Рамил безгә шофер булып урнашты. (Бу гаиләнең матбугат эшендә гомуми стажы ярты гасырдан артык.)

Авыр эшкә күнеккән Нигъмәтуллина Гакифә Салават кызы кул белән хәреф җыю осталыгын тиз үзләштерде. «Типографиянең бөтен нечкәлекләрен Рәхимова Нәсимә апа белән Мигъманова Икълимә апа өйрәтте», – ди ул. Укытучылары яхшы, үзе тырыш булгангамы, республика конкурсларында Азнакай данын яклап, «Һөнәре буенча иң яхшы» исемен алды, район хакимиятенең һәм Нәшрият, полиграфия, китап сәүдәсе буенча Татарстан дәүләт комитетының Мактау грамоталары белән бүләкләнде, рәсеме берничә тапкыр типографиянең Мактау тактасына куелды.

Төрле елларда җаваплы сәркатип һәм мөхәррир урынбасары вазыйфаларын башкарырга туры килгәч, мин бу ханымнар белән тыгыз бәйләнештә эшләдем: бергә газета чыгардык. Хәзер дә дуслыкны югалтмыйбыз. Элемтәдә торабыз. Бер-беребезнең хәлен белешәбез. Редакциядә оештырылган бәйрәмнәрдә уртак табында очрашабыз. Бер гаилә кебек без.

Нәсимә КАМАЛИЕВА,
Татарстан Республикасының
атказанган мәдәният хезмәткәре,
«Маяк» газетасы редакциясенең
ветераннар советы рәисе.
Азнакай районы

ҮЗ ИЛЕМДӘ ЯМЬЛЕ МИҢА БӘРӘҢГЕ БАКЧАСЫ ДА...

Кешене эшенә, куйган хезмәтенә карап бәялиләр. Үз һөнәренең бөтен нечкәлекләрен белгән, һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер булган белгечләр зур хөрмәткә лаек. Минем язманың герое Иске Рәҗәп авылында гомер итүче Мөнир Хәсәнов – нәкъ менә шундыйларның берсе.

Мөнир абый 1936 елда туту, эшчән колхозчы Хәсәнҗан белән Мәрьям гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. Аның балалыгы да шушы авылда үтә. Әтиләре Хәсәнҗан игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнә. Балаларын да һәр эшнең җаен белеп, тәмен табып башкарырга, пөхтәлеккә өйрәтә. Бөек Ватан сугышы башлангач, әтисе яу кырына китә һәм аңа аннан әйләнеп кайтырга насыйп булмый, сугыш кырында ятып кала. Мөнир ул чордагы яшьтәшләре кебек сугыш һәм сугыштан соңгы еллар михнәтләрен күреп үсә. Авылыбызда урта мәктәпне тәмамлагач, ул вакытта Донбасста яшәүче апасы Сания белән җизнәсе Минвәли Мөнирне үзләре янына чакыралар. Мөнир анда китеп шахтага эшкә урнаша.

– Үз илемдә ямьле миңа бәрәңге бакчасы да дип юкка гына җырламыйлар ул, сеңлем, – дип башлады сүзен Мөнир абый. – Без – авыл балаларының иң матур сабый, үсмер чакларыбыз туган нигез, туган авыл белән бәйле. Шуңа күрә кендек каны тамган җирдән каядыр читкә чыгып китеп, анда калуны хуп күрмәдем. Донбасстан кире авылыма әйләнеп кайттым. Кайтып ялгышмадым. Бәхетемне шунда таптым, – ди ул.

Аның шуннан соңгы хезмәт биографиясе һәм тормышы туган авылы белән бәйле. Биредә ул авылыбызның уңган-булган кызы Сафура белән гаилә корып җибәрәләр. Икесе дә – сугыш чоры балалары, сугыш ятимнәре. Мөнир абый колхозда төрле эшләр башкара. Чәчү, урып-җыю вакытында Минрәхим абый Хатыйпов белән бер машинада алмашлап шофер булып та эшләп ала. Башкалар белән уртак тел тапкан тырыш егетне күреп алалар һәм мәктәпкә бухгалтер итеп эшкә алалар. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз дигән гыйбарәне истә тотыпмы, авылда үскән малай табигатьне, хайваннарны яратканга-мы, зоотехник һөнәрен үзләштерергә ниятли һәм читтән торып Казан ветеринария институтына укырга керә. Мәктәптә бухгалтерия беткәч, колхозда ике ел экономист вазыйфасында да үзен сынап карый.

1970 елларда аның хезмәт юлы икенче тармак белән бәйләнә. Бу вакытта Мөнир Хәсәнов институтны тәмамлап, зоотехник белгечлеге дипломы да алырга өлгергән була. Терлекчелектә зоотехник булып эшли башлый. Малларны карауда көчен дә, белемен дә кызганмый. Ул мөгезле эре терлекләр фермасы мөдире вазыйфасын башкарырга керешә. Ул елларда терлекчелектәге хезмәт шартлары хәзерге белән чагыштырганда җир белән күк аермасы кебек иде. Һәр чорның үз кыенлыгы бар инде ул. Фермада эшләргә кайчакта терлекчеләр дә, азык та җитми. Савымчылар сенаж, саламны үзләре төяп, үзләре таратып ашата. Барлык эш кул көче белән башкарыла.

Ул елларда савымчылар сыерларны җәйләүгә барып сава иделәр. Мөнир Хәсәновка халыкны эшләтү, тыңлату кыен булмый. Ул халык белән уртак тел табып эшли.

– Тыңлата алмасам, күп еллар бу эштә эшли алмаган булыр идем, – ди Мөнир абый. – Киңәшләшеп, аңлашып эшләргә тырыштым.

Районда эш күрсәткечләре буенча да сынатмыйлар алар. 1988–1990 елларда колхозның дуңгызчылык комплексында ферма мөдире булып та эшләргә туры килә аңа. Фермада маллар саны арта. Дуңгызлар фермасында ике ел эшләгәч, Мөнир абыйны кабат сыерлар фермасына мөдир итеп күчерәләр. Ферма мөдиреннән соң хезмәт эшчәнлеген колхозда – завхоз, аннан соң профсоюз комитеты рәисе булып дәвам итә. Ялга чыккач та, урындагы хуҗалыкка ярдәм итә. Мөнир абый нинди генә эштә эшләсә дә, үзенең пөхтәлеге, төгәллеге белән аерылып тора. Эшләгән эшен яратып, аңа бар күңелен салып, илгә-көнгә файдалы булып гомер итә. Шуңа аны авылдашлары хөрмәт итә.

Тормыш тәгәрмәче гел алга тәгәри. Кышны – яз, язны – җәй, җәйләрне исә көзләр алмаштыра. Менә шул сихри дөньяның матурлыгына таң калып, тормыш итеп, гомернең узганын сизми дә каласың. Быел Мөнир абый үзенең 85 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Сафура апа белән бергә гомер итүләренең 62 нче кышын каршыларга җыеналар. Алар дүрт бала: бер малай, өч кыз тәрбияләп үстерделәр. Уллары Илдар, кызлары Илсөяр, Гөлшат, Гөлназ тормышта үз юлларын тапканнар. Тормышларына ямь өстәп, сигез оныклары, тугыз онықчыклары үсеп килә. Әнә шулай тигезлектә, татулыкта матур гомер кичереп яшәп яткан көннәре. Алар кебек тыйнак, тырыш кешеләргә, алар алып барган тормыш рәвешенә сокланмый мөмкин түгел.

Флёра ХӘЙРЕТДИНОВА,
Спас районы
Иске Рәҗәп авылы ветераннар (пенсионерлар) оешмасы рәисе

Сиксән елдан соң кайту

< Ахыры. Башы 2 нче биттә

Бүген менә аның кулында кадерле истәлек – әтисенең сугыш юлларында йөрткән шәхси әйберләре: медальон, кашык, портмане, пәкесе, патроннар... Ни хикмәт, сиксән елга якын вакыт узса да, алар әйбәт сакланган.

Дулкынландыргыч мизгелләр... Әхкыяметдин Камалетдиновның үзе үлгәннән соң «Шагнувшие в бессмертие» медален кызы кулына тапшыру бик күпләрнең күзенә яшь китерде. Юк, авылыбыз улы Әхкияметдин хәбәрсез югалмаган. Сугышның иң кайнар ноктасы – Смоленск янында барган каты бәрелешләрдә геройларча сугышып һәлак булган ул.

Табылдыкларны тапшырырга Түбән Камадан «Нефтехим» эзләнү экспедициясе әгъзалары килде. Җитәкчесе Ольга Ланцова: «Безнең эзтабарлар менә 17 ел инде яңгыр, буран дими, сазлыкларда, урман аланнарында ятып калган солдатларны эзлиләр. Менә бүгенге кебек, аларның якыннарын шатландыру, батыр исемнәрен мәңгеләштерү өчен меңәрләгән чакрым юл үтәләр. Күпме еллар узса да, ватаныбызны саклап шәһит киткән ил улларының батырлыгы онытылмый, эзтабарлар сугыш мәхшәрендә теләсә кайда җирләнгән соңгы солдатның каберен тапканчы бу игелекле эш тукталмас», – диде ул.

Очрашуда район ветераннар һәм инвалидлар оешмасы җитәкчесе Фәйрүзә Вәҗиева изге эшләре өчен

эзтабарларга зур рәхмәт белдерде һәм бер минутлык тынлык игълан итте. Авыл җирлеге башлыгы урынбасары Лилия Яковлева геройның кызына, кунакларга истәлек бүләкләре тапшырды. Нурия апаның күршесе, алты ай буена эзтабарлар белән элемтәдә торган Гөлфирә Рәхмәтуллова да сугыш ятимен шатландырганнары өчен эзтабарларга рәхмәтен җиткерде.

Тәнзилә ШӘЙХНУРОВА,
Күзкәй авылы китапханәчесе.
Тукай районы

ТУГАН ҖИР ХУҖАЛАРЫ

Авыл тәмле йокыда, тик бер өйдә генә сүрән ут яктысы шәйләнә. Без – алты малайны уятырга теләмичә, инәкәй ярты гәүдәсен сугыш алган әткәй белән күзләреннән генә аңлашып, төннең саран караңгылыгы эчендә мичнең акрын гына пыскуына күз сала да, кышкы зәмһәрир салкынны яра-яра, авылның икенче башында чакрым җирдәге урта мәктәпне җылытырга дип ашыга. Бер арадан каенанасы Сабира әби ишек келәсен элеп кала.

Мәктәп җылысы

Инәкәй барып җитүгә, аның кебек тагын дүрт хатын җәйге утын пүләннәрен ничә дистәләгән мичләргә ягарга тотыналар. Ул утын пүләннәрендә безнең көч тә бар: өлкән сыйныфларга җиткәндә әниләр урынына аркылы пычкы-балталар белән урман кисәргә китәбез. Монда күп өлеш Альберт энекәшкә туры килә иде: таза беләкле, нык-лы-батыр гәүдәле булганы өчен, әлбәттә. Мөгаллимнәребез – бик тә ихлас, беркатлы Зиннур, Хәйдәр абыйлар җитәкчелегендә йөзәрләгән машина агач кул көче белән киселеп, ерактагы мәктәп ихатасына кайтарыла да, тоташ озын бүрәнә бинаны җылытырга дип, әниләребез янәдән аркылы пычкы белән кузлаларга салып кисеп-ярып, таучык-таучык утын пүләннәре өяләр.

Бу иске агач бинаның тәбәнәк классларында һәркемне үзенә җәлеп итә торган төрле түгәрәкләр, спорт секцияләре кичке караңгыларда да гөрләп тора иде. Гел үзенә тартучы физкультура, хезмәт укытучыбыз Галимҗан абый, күп көннәрдә дәресләр башланганчы 300ләп укучыны линейкага тезеп, нәкъ менә безнең Альберттан физзарядка ясата һәм бөтенебез аны кабатлыйбыз, чөнки ул – җиңел атлетика, чаңгыда шуууда мәктәп чемпионы. Җәен дә шундый хәрәкәтчән, өлгер ул. Каникулларда я бергәләп урман кисүдә, урак җиткәч, күтәрелмәле риге-амбарларга, атка төяп, 120шәр центнер гәрәбәдәй бөртек-орлык кертүләр (шуннан аена ул вакыт өчен күп кенә егетләрнең кесәсенә 120шәр сум), тагын гаиләбез белән гектарлаган борчак чабулар. Инде дүртенче сыйныфта ук күршебез Әсхәбетдин абыйның атын тотып йөреп фермага яшел борчак кайтарулар, басуда шикәр чөгендере чүпләрен утаулар, чалгы чүкүче сугыш инвалиды әтиебезгә ияреп Ык буендагы печән чабучыларга сулар ташып торулар, аннары атлы арбаларда узышып кайтулар – болар һәммәсе дә эшсөярлеккә тәрбия биргән, шуңа да энекәш белән бик сагынып искә төшерәбез ул әкияти чакларны. Бәләкәйдән йомраннар тотып (тешләгән эзләре әле дә кулларда), сарык, бозауларны Стәрле, Ык буе үзәнлекләрендә карап-көтеп йөрүләр, мәктәптә дистәләгән читлекләрдәге куяннарга Стәрле буе алларын кочак-кочак ташулар да аның күңелендә мал җанлы булуга бик нык тәэсир иткәндер. Өстәвенә әтиебез янына тирә-якта данлыклы ветеринария остасы – мал врачы, безнең кебек ишле балалы Сәгыйдулла абый еш килә, гел шул малкайларның саулыгы хакында сөйли. Аның өйгә керүгә сәлам бирүе дә: «Хаҗи, малкайларыңның хәле ничек?» – дип белешү-кайгыртудан гыйбарәт иде. Менә болар, билгеле, Альберт энекәшкә унынчы сыйныфны тәмамлауга, ике дә уйламыйча, Казан ветеринария институтында укырга дигән төпле фикерне тудырган да. Һәм алар авылдан имтиханга дүрт егет китеп, ул гына кереп кайтканы да хәтердә.

Студент чак

Беренче курсны тәмамлап, авылга кайткач, танылган техника остасы Мәхәим Хәйруллинда комбайнчы ярдәмчесе булып эшли. Әнә шулай һәр җәйдә тырыш хезмәттә – аеруча Бигеш аэропортын төзүдә катнашу, Пермь якларында урман кисеп, сал агызулар нык истә калган. Берчакта да өйдән акча көтми (анда болай да ишле бала – энекәшләр), укудан тыш төннәрен, ялларда эшләп, үз көнен үзе күрә. Җәен акча эшләп, аны көтеп торган (әтиебез сугыш яраларыннан 46 яшендә кинәт бакыйлыкка күчә) дүрт энекәшенә кием-салымнар төяп кайта. Телевизорга тикле ала – менә сиңа студент.

Өченче курста Ленино-Кокушкино авылы хуҗалыгы фермаларында практика үткәндә кешеләрне янгыннан коткаруы турында «Социалистик Татарстан» газетасында да язып чыккач, аның батырлыгын республикада да белделәр. Кичен клубтан кайтканда кинәттән каршы яктагы йортны ут ялмап алуны күрүгә, өйнең ишеген ача алмагач, тәрәзәсе аша эченә сикереп үтә: ялкыннан әнисе белән ике баласын алып чыга да халык җыелганчы утны сүндерә Альберт. Кайберәүләр кебек, медаль артыннан йөрми – гадәте андый түгел: гәрчә ул аңарчы да суда батучы үсмерне коткарган була.

Дипломлы белгеч 1974 елда туган авылы Югары Стәрледә – Мичурин исемендәге колхозда баш ветеринария табибы булып эшли башлый. Икенче елны армия сафларына алалар. Владивостоктан ерак Олга бухтасында космик-ракета гаскәрләре частенда замполитны яхшы хезмәте өчен ялга да кайтаралар. Аннары яшьнәп торган чак дип тормышның нык-лап кайнаган Чаллы – Кама төбәген сайлый: ике ел Түбән Каманың «Коммунизм байрагы» совхозында, алты ел КамАЗның авыл хуҗалыгы буенча баш ветеринария табибы, яңадан Чаллы нәселле терлекләр әзерләү үзәге директоры урынбасары булып эшли. Шуннан институтта аңардан бер елга алда гына укыган Мамадыш райкомы беренче секретаре Фатих Сибагатуллин аны үзенә чакыра.

Мамадыштан – Урманайга

– Яшь барган саен туган җир тарткач, Урманайга кайтып, хезмәт биографиямдә төп урынны биләвемә бер дә үкенмим, – ди Альберт.

Әйе, биредә 17 елдан артык тоташтан иң дәвамлы фидакарь хезмәт куйган директор ул. Саный китсәң, яңа ындыр табаклары, терлекләр өчен сулары-чишмәләре җайлаштырылган, механикалаштырылган ике җәйге лагерь, складлар салына, ферма биналарына өр-яңадан реконструкцияләү, хезмәт процессларын механикалаштыру үткәрелә. Мөгезле эре терлекләр 460тан 1170 башка җитә, аеруча савым сыерлары артып, районда иң алгы сафка чыгалар. Көнбагыш мае сыгу цехы ачыла, умарталык икегә җиткерелә. Авыл инфраструктурасын яңарту-төзекләндерүдә күп көч куела. Аеруча авылны газлаштырудагы фидакарьлеген билгеләп узарга кирәк аның.

2007 елның язында 460 гектар чәчүлек җире, 700 мең сум кредит алып фермерлык эшен башлый ул.

– Буыннар эстафетасын лаеклы тапшыру, дәвамчыларны Җир-анага беркетеп калдыру минем мактаулы бурычым иде, – ди Альберт.

Дәвамчылары, таянычы дип үзенең ике улы Алмас белән Илназны күздә тотып әйтүе аның. Алар кечкенәдән фермерлык эшчәнлеген үз җилкәләрендә тоеп-белеп үсәләр. Хәзерге көндә 460 гектар сөрүлек җире, 200 баш мөгезле эре терлеге бар, бер үк вакытта умарталыгыннан да кайтып керми. Заманча яңа технологияләр кертеп, тотрыклы игенчелек, терлекчелек продукциясе җитештерү – аларның төп максаты. Соңгы вакытта ашлык суктыру комбайны, 5 трактор, чәчкеч, туфрак эшкәртү агрегатлары белән баету тагын да яңа мөмкинлекләр ача. Быел да, корылыклы җәйгә карамастан, уңышлары әйбәт кенә булды.

Авыл хуҗалыгы министрлыгы, район хакимияте белән һәрдаим үзара хезмәттәшлектә булып, аталы-уллы фермерлар югары нәтиҗәлелеккә ирешү өчен бөтен көчләрен куялар, дәүләт ярдәменә дә – өстенлекле грантларга, программаларга таяналар. Туган җирдәге нигезләре никадәр төпле-ныклы булса, киләчәкләре, авылның иртәгәсе дә ышанычлы.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы

Шигърият

Ветераннар

Картаймагыз әле, ветераннар,
Ауропаны саклап калган ирләр;
Хәтерлиләр сезне данлы юллар,
Хәтерлиләр сезне азат илләр.

Илләр җырлый бәйрәм көннәрендә,
Сезнең яшьлек – җиңү көйләрендә.
Сез аларга ирек китердегез,
Шатлык китердегез өйләренә.

Картаймагыз әле, ветераннар,
Илгә дан китергән тынмас җаннар.
Сезгә тиеш әле бик күп назлар,
Сезгә тиеш әле бик күп язлар.

Гәрәй РӘХИМ

Билгесез солдат

Һәйкәл тора. Имеш, сөйлиләр,
Бу – билгесез солдат һәйкәле.
Билгесезме шушы бакыр кеше?
Билгесезме, хәтер, әйт әле?!

Атакага күтәрелдек бергә,
Ега сукты әҗәл бер мәлне,
Вакытлыча янә терелдем мин,
Ул мәңгелек сынга әйләнде.

Каршысында түтәл-түтәл гөлләр
Изге ялкын булып яналар,
Баш өстендә таңнан кошлар сайрый,
Эргәсендә сайрый балалар.

Ә артында аның чал бер хатын
(Ил әнисе – улдыр, мөгаен.)
Ничәмә ел инде өнсез елый,
Салкын ташка бәреп маңгаен.

Җиңү! Кояш балкый бер битеңдә,
Бер битеңдә – моңсу ай һаман.
Бер күзеңнән шатлык нуры сибелә,
Бер күзеңнән әче яшь тама...

Мостай КӘРИМ

Бабамның медальләре

Бабамның медальләре күп,
Яңа костюмы тулы.
Тик бабамның – разведчикның
Терсәктән юк сул кулы.

Батырлыгы өчен аңа
Унлап медаль биргәннәр.
Алар шул куркак булмаган,
Разведкага йөргәннәр!

Немецлар тылына кереп,
«Тел» алып кайткан чакта,
Бомбалар шартлап ярылган
Туктаусыз алда, артта.

Менә шунда яраланган
Бабамның сыңар кулы.
Таза чакта ничә тапкыр
Айкаган немец тылын.

Ерак илләрдә булган ул,
Бик күп шәһәрләр алган!
Яңа батырлыклар эшләп,
Медальләр тага барган.

Мин сокланып карыйм аңа,
Баһадир безнең бабай!
Әмма үзе бик аз сүзле,
Мактанмый бер дә алай.

Самат ШАКИР